ЦЕНТР СЕМЬИ И ДЕМОГРАФИИ
АКАДЕМИИ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# ГАИЛӘ – МИЛЛӘТ НИГЕЗЕ

*Татар мәгърифәтчеләре гаилә һәм тәрбия мәсьәләләре хакында*

**3 том**
**Каюм Насыйри**
**Тәрбия**

# СЕМЬЯ – ОСНОВА НАЦИИ

*Татарские просветители о семье и воспитании*

**3 том**
**Каюм Насыри**
**Воспитание**

Ижевск, 2015

**УДК 37.01(470.41)"18"**
**ББК 74.03(2Рос.Тат)5**
**С309**

Научный редактор: д.с.н. Ильдарханова Ф.А.
Рецензент: д.и.н. Загидуллин И.К.

Подготовка текста и перевод:
кандидат филологических наук
**Абызова Резеда Равиловна**

С309 Семья – основа нации. Татарские просветители о семье и воспитании. Т. 3. Каюм Насыри. Воспитание. – Ижевск, 2015. – 192 с.
ISBN 978-5-9222-0704-1
ISBN 978-5-9631-0335-7 (т.3)

Настоящее издание, представляющее собой третий том серии «Татарские просветители о семье и воспитании», посвящено татарскому ученому и просветителю Каюму Насыри. В него вошли наиболее значимые по своей воспитательной и образовательной ценности произведения писателя – «Книга о воспитании» и «Трактат о нравственности». Данные литературные труды, несмотря на прошествие с момента их написания почти двух столетий, по сей день сохранили свою познавательную и эстетическую значимость. Они, несомненно, привнесут свой вклад в формирование духовно-нравственного мировоззрения и современного читателя.

---

Фәнни мөхәррир: с.ф.д. Илдарханова Ф.Ә.
Рецензент: т.ф.д. Заһидуллин И.К.

Текстны эшкәртүче һәм тәрҗемә итүче:
филология фәннәре кандидаты
**Абызова Резеда Равил кызы**

«Татар мәгърифәтчеләре гаилә һәм тәрбия турында» сериясен дәвам иткән чираттагы өченче том бөек татар язучысы һәм мәгърифәтчесе Каюм Насыйрига багышланган. Әлеге китапка әдипнең әхлак һәм әдәп мәсьәләләрен яктырткан «Тәрбия китабы» һәм «Әхлак рисаләсе» кебек әсәрләре тупланган. Бу әдәби ядкярләрнең язылу вакытыннан алып ике гасырга якын ара үткән булса да, аларның эстетик һәм мавыктыргыч әһәмияте әле дә үз кыйммәтен югалтмаган. Һәм алар, һичшиксез, бүгенге көн укучысының да рухи һәм әхлакый карашларын формалаштыруга үз өлешен кертер дип ышанып калабыз.

---

**ISBN 978-5-9631-0335-7 (т.3)**
**ISBN 978-5-9222-0704-1**
**© Центр семьи и демографии АН РТ, 2015**
**© Изд-во ООО «ПРИНТ», 2015**



# КАЮМ НАСЫРИ
## (1825-1902)

*Каюм Насыри – первый из наших мусульман, которого европейское образование, полученное им в Казанском университете, подняло в умственном отношении на такую высоту, что он мог отнестись к нему объективно.*

*В.В. Григорьев (1816-1881), ученый-востоковед,*
*профессор Санкт-Петербургского университета*

# Кереш

2012 елда Татарстан Фәннәр академиясенең «Гаилә һәм демография фәнни-тикшеренү үзәге», XIX гасыр азагы – XX гасыр башында яшәгән татар мәгърифәтчеләре мирасын өйрәнүне, тәрҗемә һәм нәшер итүне күздә тотып, «Гаилә – милләтнең нигезе» исемле проект әзерләде. Әлеге проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә татар халкының күренекле вәкилләре – Габдулла Бубый (1871–1922) һәм Ризаэтдин Фәхретдин (1859–1936) иҗатларына багышланган хезмәтләр дөнья күрде[1].

2015 ел Россия Федерациясендә Әдәбият елы дип игълан ителде. Шул уңайдан «Гаилә һәм демография фәнни-тикшеренү үзәге» тарафыннан басмага күренекле татар язучысы, галим һәм мәгърифәтче Каюм Насыйри (1825–1902) шәхесенә багышланган өченче том әзерләнде.

Габделкаюм Габденнасыр улы Насыйров – Каюм Насыйри – 1825 елның 2 февралендә Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Югары Шырдан авылында укымышлы мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылында ала. 1841–1855 елларда Казанда мәдрәсәдә укый. Яшьтәшләре арасында үзенең зирәклеге белән аерылып торучы булачак әдип гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә, шулай ук яшерен рәвештә рус телен дә әкренләп үзләштерә башлый.

[1] Гаилә – милләт нигезе. Татар мәгърифәтчеләре гаилә һәм тәрбия турында. Т. 1. Габдулла Бубый. Хатыннар. Казан: Отечество, 2013. – 357 б.
Гаилә – милләт нигезе. Татар мәгърифәтчеләре гаилә һәм тәрбия турында. Т. 2. Ризаэтдин Фәхретдин. Гаилә. Казан: Отечество, 2013. – 240 б.

1855 елда Каюм Насыйри Казанда әүвәл Духовное училищеда, соңрак шуның дәвамы булган семинариядә татар телен укыта башлый, булачак руханиларны татар халкының мәдәнияте, тарихы, әдәбияты белән таныштыра. Үзенең белемен үстерү һәм камилләштерү максаты белән Каюм Насыйри Казан университетына ирекле тыңлаучы булып керә. Бу исә ул чор татар мохите өчен сирәк күренешләрдән санала[2].

Рухани уку йортларында 15 ел эшләгәннән соң, 1871 елда Каюм Насыйри татар балаларына рус телен укыту өчен үз мәктәбен ача. Әмма 1876 елда, консерватив фикерле татарларның галимнең эшчәнлегенә карата тискәре карашлары, шулай ук рус-татар мәктәпләре инспекторы В.В. Радлов белән укыту методикасы мәсьәләләрендә килеп чыккан каршылыклар нәтиҗәсендә, Каюм Насыйри мәктәптәге эшен калдырып, үзенең калган гомерен фәнни һәм әдәби иҗатка багышлый.

Каюм Насыйри – татар әдәбияты тарихында күренекле урынны алып торган шәхесләребезнең берсе. Бу могтәбәр затның эшчәнлеге күпкырлы: аның фәнгә әдәбият, тел белеме, математика, медицина, педагогика, тарих, география өлкәләренә караган хезмәтләре билгеле. Галимнең күпсанлы фәнни хезмәтләре һәм уку әсбаплары арасында «Мәҗмәгыл-әхбар» (1859), «Нәху китабы» (1860), «Хисаблык» (1873), «Зөбдәте мин тәварихе рус» (1890), «Гильме һәндәсә» (1895), «Истилахате джаграфия» (1890), «Джаграфия кабир» (1894–1899), «Әнмүзәҗ» (1895) кебек китапларны атап китәргә мөмкин.

1885 елда Каюм Насыйри Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы итеп сайлана.

---

[2] Гайнуллин М. Каюм Насыри // Каюм Насыри. Избранные произведения. Казань: Татарское книжное издательство, 1977. – с. 4.

Белгечләр әлеге вакыйганы галимнең фәнни эшчәнлегенең танылуы дип тә билгели[3].

Каюм Насыйриның татар әдәбияты үсешенә керткән өлеше дә зур була. Әдип «Кырык бакча», «Тәрбия китабы», «Әхлак рисаләсе», «Әбүгалисина кыйссасы», «Кырык вәзир» һ.б. күп кенә әсәрләр авторы[4].

Каюм Насыйри үз әсәрләрендә әхлак, иман, гаилә мөнәсәбәтләре, традицияләре, бала тәрбиясе кебек мөһим мәсьәләләрне яктырта. Әдип уңай әхлакый сыйфатларны үзенең укучысы өчен үрнәк итеп куйса, кешенең рухи үсешенә комачаулый торган сыйфатларны мавыктыргыч хикәяләр, әдәби чаралар ярдәмендә тәнкыйтьләп фаш итә.

Мисал өчен, Каюм Насыйриның 113 нәсихәттән торган «Тәрбия китабы» үсеп килә торган буыннарны тәрбияләүдә ярдәм итәчәк төпле киңәшләр җыентыгыннан гыйбарәт. Акыл ияләре һәм гади халык тормышыннан мисаллар китереп, автор төрле вакыйгаларны тасвирлый һәм шулар нигезендә нәтиҗәләр ясый. Ул нәтиҗәләрнең, үгет-нәсихәт формасында булмыйча, тормыштан алынып, гади киңәш кебек итеп бирелүе укучыны әхлакый уйлануларга этәрә.

Каюм Насыйриның «Әхлак рисаләсе» исемле китабы да тәрбия мәсьләләренә багышланган. Биредә әдип кечкенә генә нәсихәтләр ярдәмендә акыл һәм наданлык, тырышлык һәм ялкаулык, тугрылык һәм икейөзлелек, юмартлык һәм саранлык, батырлык һәм куркаклык

[3] Шунда ук. 5 б.
[4] Каюм Насыйриның хезмәтләре дөнья күргән басмалар: Насыйри К. Әсәрләр. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1971; Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1974; Насыри К. Избранные произведения. Казань: Татарское книжное издательство, 1977; Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2003-2006 һ.б.

кебек сыйфатлар турында үз фикерен белдерә, укучысына камил әхлак тәрбияләүдә ярдәм итәчәк киңәшләрен, тәкъдимнәрен бирә.

Мәшһүр мәгърифәтченең әсәрләре укытучылар, ата-аналар, балалар өчен өстәл китабы булырга лаеклы. Аларда хәзерге заманда да актуаль булган гаилә кыйммәтләре хакында сүз бара. Гаилә милләтнең терәге һәм байлыгы буларак бәяләнә. Әхлак, тәрбия мәсьәләләре, гаиләдәге мөнәсәбәтләргә зур игътибар бирелә. Каюм Насыйри әсәрләренең язылу вакытыннан алып ике гасырга якын ара үткән булса да, аларның эстетик әһәмияте әле дә үз кыйммәтен югалтмаган. Һәм алар, һичшиксез, бүгенге көн укучысының да рухи һәм әхлакый карашларын формалаштыруга үз өлешен кертер дип ышанасы килә.

*Әлеге китап Каюм Насыйриның тууына 190 ел тулуга багышлана.*

Ф.Ә.Илдарханова, социология фәннәре докторы,
Р.Р.Абызова, филология фәннәре кандидаты

*Каюм Насыйри*

# *Тәрбия китабы*

# Тәрбия китабы[5]

Ягъни балаларны тәрбия кылмак бәянында бер китаптыр. Әмма тәрбия кылмак вә тәрбия итмәк дигән сүз фәкать ашатып-эчертеп үстермәк мәгънәсендә генә түгелдер, бәлки ашатып-эчертеп үстермәк, вә баланың холкын, фигылен ислях кылмак вә төзәтмәк, вә хайванидан чыгарып, инсаният дәрәҗәсенә китермәк, вә тәгълим бирмәк, вә өйрәтмәк, вә укытмак, вә әдәп нигезе бирмәк мәгънәсендәдер. Ошбу рисаләдә зикер кылыначак хикәятләр, вәгазьләр вә нәсихәтләр һәммәсе, вә бу рисаләнең һәрбер кәлимәсе – бер тәрбиядер, шул җәһәттән «Тәрбия китабы» дип ат бирдек.

*Беренче тәрбия.* Бер хәким балаларга шундый нәсихәт бирде ки: «Әй җаннарым, угланнарым, нәсихәтне ишетегез, һөнәр өйрәнегез. Дөньяның милкенә вә дәүләтенә ышанырга ярамас. Алтын-көмеш сәфәр кешесенә хәтәрдер, вә йорт-җир кешесенә дәхи хәтәре бар: я угры алып китәр, яки утка янып китәр. Әмма һөнәр – бер агым судыр вә ышанычлы дәүләттер; һөнәр иясе әгәр дәүләттән төшсә дә, кайгы юк. Инде, әй угыл, бу урында максуд бер хикәят түгелдер. Син дә шулай ук һөнәр өйрән, тәрбия өйрән, гыйлем өйрән».

*Икенче тәрбия.* Мәшәехләрдән бер мәшәехкә бер адәм шикаять кылды ки: «Фәлән кеше, минем бозык эшләремне сөйләп, фәлән җирдә мине яманлаган», – диде. Ул мәшәех әйтте ки: «Син аның яхшы эшләрен сөйләп, аны оятлы ит», – диде. Бу дәхи сиңа бер тәрбиядер. Әй угыл, һәрбер хикәяттән бер мәгънә фәһем иткәйсән

[5] Тәрҗемә 1891 елгы басма нигезендә башкарылды:
Насыйри Каюм. Китаб әт-тәрбия. Казан: Казан университеты табыгханәсе, 1891. – 32 б.

ки, аңсыздан берәү сине бер җирдә яманлаган булса, аңа каршы син аны макта. Шаять ки, ул үзе дә, адәм булса, инсаф итәр вә оялыр.

*Өченче тәрбия.* Бер падишаһның берничә углы булып, араларыннан берсе – зәгыйфь, кыска буйлы, кечкенә нәрсә иде. Гайреләре озын буйлы, хуб руйлы иделәр, әмма аталары ул углына җирәнү вә кимсетү белән карар иде. Ул углы бер зиһен иясе вә мәгърифәтле бала иде. Әйтте: «Әй ата, гакыллы тәбәнәк надан озыннан яхшырак түгелме? Һәрнәрсәнең кыйммәте күләменә карап йөрмидер. Мунча ташы бик эре, йөге бер тәңкә, энҗе бик вак, мыскалы ун тәңкә», – диде. Аталары вә дәүләтнең зур кешеләре барчасы көлештеләр вә тәхсин кылыштылар... Бәс, әй угыл, гыйлем вә мәгърифәт дигән нәрсә буйга вә кыяфәткә карап булмыйдыр.

*Бишенче тәрбия*[6]. Локман хәкимнән сорадылар: «Син хикмәтне кемнән өйрәндең?» – диделәр. Әйтте: «Күзсез кешеләрдән өйрәндем, чөнки алар аяк басасы урынны күрмәенчә аяк басалар», – диде... Әй угыл, монда сиңа тәрбия шулдыр ки: Локман хәкимнең сүзен яхшы фәһем итеп кара, ягъни ул: күзсезләр аяк басасы урынны күрмичә, я абыналар, яки төртеләләр, яки егылалар, шулай ук аңы юк кешеләр вә наданнар – сүзнең урынын белми сөйләшәләр вә ахырын уйлап сөйләшмиләр. Аларның наданлыкларын күрдем дә хәким булдым», – диде.

*Алтынчы тәрбия.* Олуглардан бер адәм үзенең углын бер галим остазга тәгълим вә тәрбия өчен тапшырды. Вә әйтте ки: «Әй остазы камил, ошбу баланы тәрбия кыл вә укыт ки, галим вә гакыйл булсын», – диде. Берничә мөддәт[7] бу баланы остаз тәрбия кылды вә укытты. Әмма һичбер гыйлем әсәр кылмады. Ул баланы атасына

---

[1] Каюм Насыйриның гарәпчә басмаларына ниндидер сәбәпләр белән 4, 32, 47, 101, 109, 110 нчы тәрбияләр кертелмәгән.

[7] мөддәт – вакыт

кайтарып җибәрде. Әйтте: «Бу бала һичбер белемгә сәләтле түгелдер, хәтта үземне дивана кылды», – диде.

*Җиденче тәрбия.* Бер падишаһ диңгездә бер көймәдә сәфәр кылганда күрде: бер егет бар, моңарчы көймәгә утырганы юк, имеш. Вә көймәнең мәшәкатен күргәне юк, имеш. Куркып егълап утырыр, дер-дер калтырар. Никадәр юатып карадылар, егълаудан һәнүз[8] туктамый. Падишаһ дәхи хафа булды. Анда бер хәким бар иде, әйтте: «Әй әфәнделәр, әгәр боерсагыз, мин бер хәйлә кылам: шаять, сабыр итәр», – диде. Падишаһ әйтте: «Белгәнеңне эшлә», – диде. Бәс, хәким әмер итте. Бу егетне бәйләп дәрьяга аттылар, бер-ике мәртәбә чумдырып, янә көймәгә алдылар. Бу егет үлемнән терелеп кайткан кебек хәйран булып, бер дә дәшмичә утырды, күңеле карар тапты. Падишаһ моны бик тәхсин кылып, хәкимгә әйтте: «Я хәким, монда ни хикмәт бардыр?» Хәким әйтте: «Ул егет әүвәл көймәнең мәшәкатен вә су сәфәрен күргәне юк, янә гаркъ булуны белгәне юк, вә көймәдә сәламәт йөрүнең кадерен белгәне юк, имеш», – диде. Монда сиңа тәрбия шулдыр, әй угыл: шулай ук адәм гафиятьнең[9] вә сәламәтлекнең кадерен бер михнәткә дучар булгач беләдер.

*Сигезенче тәрбия.* Бер падишаһ углының атасыннан калган күп хәзинәсе бар иде. Кәрим вә юмартлык кулын ачты, вә үзенең гаскәр халкына вә рәгыйятенә[10] ниһаятьсез хәзинәләр түкте. Бер вакытны бер тәдбирсез[11] нәдимләреннән[12] берсе нәсихәт әйтте: «Әй шахзадә, мөкаддәмдәге[13] падишаһлар бу хәзинәне иҗтиһад[14] белән хасил иткәннәрдер, вә бер мәслихәт өчен хәзерләгәннәрдер. Син азрак

---

[8] һәнүз – һаман
[9] гафият – тәннең сәламәтлеге, исәнлек, саулык
[10] рәгыйять – бер дәүләт кешеләре
[11] тәдбирсез – ахырын уйламаучы
[12] нәдим – иптәш
[13] мөкаддәмдәге – элеккеге
[14] иҗтиһад – тырышлык

кысыбрак тот, вакыйгалар алдадыр, хәзинәнең хаҗәт вакыты килер», – диде. Шаһзадә аның мәслихәтен мәгъкуль күрмәде. «Аллаһы Тәгалә миңа бу мөлкәтне бирде, ни була, ашармын, эчәрмен, бирермен, мин ул хәзинәгә каравылчы булганым юк», – диде. Әй угыл, урынсыз саранлык кылырга да ярамый.

*Тугызынчы тәрбия.* Ике борадәр[15] бар иде. Бере падишаһ хезмәтендә булып гомер кичерер иде. Бере үзенең кул көче белән хасыйл[16] итеп тереклек кылыр иде. Бервакытны ул падишаһ хезмәтендәге бай борадәр әйтте: «Әй борадәр, ник падишаһ хезмәтенә кермисең? Таки каты хезмәтләрдән котылыр иден», – диде. Ул борадәр әйтте: «Син ник кул көчең белән тереклек кылмыйсың? Таки хезмәт хурлыгыннан вә тәнәззелдән[17] котылыр идең. Хәкимнәр әйткәннәрдер ки, үз икмәгеңне ашап өйеңдә утыруың кеше хезмәтендә алтын кәмәр баглавыңнан артыкракдыр»... Үз көчең белән тапкан бер тиенең миннәт[18] белән хасыйл булган мең тиеннән бәрәкәтлерәкдер.

*Унынчы тәрбия.* Нуширван падишаһ сараенда бер груһ хәкимнәр бер мәслихәт хосусында сөйләшеп утырырлар иде. Ул мәҗлестә Бөзәрҗөмһөр һәм бар иде. Әмма ул һич сүз дәшмичә сөкүт[19] кылып утырыр иде. Әйттеләр: «Я, Бөзәрҗөмһөр, син бу хосуста безнең сүзебезгә бер дә катышмыйсың», – диделәр. Бөзәрҗөмһөр әйтте: «Вәзирләр – табиблардыр, авыру түгел кешегә дару бирмиләр. Мин күрәмен ки, сезнең рәиегез[20] растдыр, бу тәкъдирдә минем катышуымның хикмәте бер дә юктыр», – диде. Әй угыл, Бөзәрҗөмһөрдән сиңа тәрбия шулдыр ки: хәкимнәр булып

[15] борадәр – ир туган
[16] хасыйл – табыш
[17] тәнәззел – кимсетелү
[18] миннәт – ярдәм, булышлык
[19] сөкүт – дәшми тору, сөйләшми тору
[20] рәи – караш, фикер

хәкимнәр урынсыз җирдә кеше сүзенә катышмадылар. Кешенең сөйләшә торган сүзен кисеп сүз әйтмәк мәзмүм[21] холыктыр. Әгәр кеше сүзенә катышмакчы булсаң, мәҗлесдәшләрең сүздән туктаган арада сүзгә катыш.

*Унберенче тәрбия.* Искәндәр Румидан сорадылар: «Мәшрикъ вә мәгъриб диярен[22] ничек итеп алдың? Мөкаддәмдәге падишаһлар никадәр гаскәр вә акча, вә хәзинә түгеп тә ала алмаганнар иде», – диделәр. Искәндәр әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән алдым, һәр мәмләкәтне алдым, халкын рәнҗетмәдем. Вә элгәре падишаһларын изгелектән гайре нәрсә белән зикер кылмадым», – диде. Әй угыл, имде күрдең, нинди тәрбияле кешеләр бар, имеш. Хилем вә йомшаклык белән бөтен мәмләкәтне тәсхир[23] кылалар; хилем вә йомшак сүзле булырга тиеш, гәрчә дошманың булса да, изгелектән гайре зикер кылма.

*Уникенче тәрбия.* Олуглардан берәү бер падишаһтан сорады: «Фәлән заһид[24] хакында ни әйтәсең? Бәгъзеләр аның хакында тагына кылалар», – диде. Ул падишаһ әйтте: «Мин заһирән[25] гаеп күрмимен, әмма батыйны[26] гаиптыр[27]. Гаипка хөкем итә алмыймын», – диде.

Әй угыл, фәкать үзеңнең гөманың[28] белән генә бу кеше фәләндер дип, кеше өстенә гаеп исбат итмәк хатадыр. Моны сүи зан[29] диерләр, хәрам эшдер, моннан саклан.

---

[21] мәзмүм – начар
[22] дияр – илләр
[23] тәсхир – яулап алу
[24] заһид – дөнья эшләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән генә шөгыльләнүче ир кеше
[25] заһирән – тышкы яктан
[26] батыйн – эчке як, күңел
[27] гаип – күз алдында булмау, сер
[28] гөман – шик
[29] сүи зан – начар уй, явыз фикер

*Унөченче тәрбия.* Шәех Сәгъди димешдер ки: «Габделкадыйр Гилянины күрдем. Кәгъбәдә башын ташка куеп әйтәдер ки: «Әй Ходавәндә, гафу кыл, әгәр кыямәттә гокубәткә[30] мөстәхикъ[31] булсам, каберемнән күзсез итеп куптар, таки изгеләр алдында оятлы булмагай идем», – дидер. Әй угыл, дөньяда бер кечкенә генә гаебең булса, кеше күзенә күрсәтергә ояласың. Кыямәттә пәйгамбәрләр, изгеләр вә җәмигъ халык алдында гаебеңне вә гөнаһыңны йөзеңә бәрсәләр, анда качарга урын юк. Инде сиңа тәрбия будыр ки: ахирәттә йөзеңә киләсе гаепне эшләмә. Габделкадыйр Гиляни кебек адәмнәр курыксалар, сиңа, миңа ни сан? Иман китермәк фарыздыр.

*Ундүртенче тәрбия.* Изгеләрдән бер адәм бер падишаһны төшендә күрде – оҗмахта утырыр. Вә дәхи бер фәкыйрь суфины күрде – җәһәннәмдә газапта, имеш. Сорады: бу падишаһ бу дәрәҗәне ни белән тапты да, бу фәкыйрь суфи бу түбәнлеккә ни сәбәпле төште? Без моның хилафын[32] гөман кыйладыр идек», – диде. Әйттеләр: «Падишаһ фәкыйрьләрне вә дәрвишләрне сөйгән өчен оҗмахлык булды. Әмма бу фәкыйрь падишаһларга якынлыгы сәбәпле җәһәннәмлек булды», – диделәр... Залимнар таифәсенә вә нәфесенә золымлык кылгучыларга якынлык дәхи ислам шәэне түгелдер.

*Унбишенче тәрбия.* Юнан вилаятендә бер кәрванны талап, хисапсыз малларын алып киттеләр. Сәүдәгәрләр бик еглаштылар, Аллаһы Тәгаләдән ярдәм теләделәр. Ни файда?! Ул кәрван эчендә Локман Хәким бар иде. Берәү әйтте: «Я Хәким, ул угрыларга берничә хикмәт кәлимәләре әйтче, таки малларыбызны кайтарып бирсеннәр», – диделәр. Локман әйтте: «Аларга хикмәт кяр кылмас. Ягъни кара күңелгә хикмәт вә вәгазь әсәр итмәс, ташка кадак кагып

---

[30] гокубәт – азап, җәза, авырлык
[31] мөстәхикъ – лаек
[32] хилаф – каршы, кире, тискәре

булмыйдыр», – диде. Әй угыл, вәгазьләр бар, насыйхлар бар, бәгъзесенең вәгазьләре вә нәсихәтләре әсәрле түгелдер. Вәгазь әсәр итмәгәнлек күп вакытны вәгазь итүченең пәрһиз түгеллегендәндер.

*Уналтынчы тәрбия.* Локман Хәкимнән сорадылар: «Син әдәпне кемнән өйрәндең?» – диделәр. Локман әйтте: «Әдәпсезләрнең әдәпсезлеген күреп, үземә килешмәгән кебек булды да, һаман андаен фигыльләрдән саклана килдем, әдәпле булдым», – диде. Әй угыл, гакыллы балага атлам саен гыйбрәтләр бар, вәгазьләр бар, мәгърифәт хасил итә күр.

*Унҗиденче тәрбия.* Хикаять кыйланмыштыр ки, бер заһид кичендә бик күп тәгам ашап, сәхәргә кадәр бер хәтем белән намаз укый, имеш, диделәр. Моны бер гакыл иясе ишетеп әйтте: «Кяшки бичара ярты кадак икмәк ашап ятып йокласа, күп артык булыр иде». Әй угыл, корсакны күп тутырмак хикмәткә мөнафидыр.

*Унсигезенче тәрбия.* Шәех Сәгъди хикмәт кылмыштыр ки: «Бер сәфәребездә бер кичне уяныр күрдем ки: кәрван эчендә бер адәм бөтен төн нәгъръә белән бәет вә шигырь әйтеп, асла йокламаенча кичне уздырды. Ни хәл дип сорадым. Әйтте ки: «Былбылларны күрдем ки: агачтан агачка очып налә вә фәган кылалар. Киекләр таулардан налә вә фәган кылалар. Бакалар судан налә вә фәган кылалар. Хайваннар урманнардан налә вә фәган кылалар. Бәс фикер кылдым ки: һәммә җан ияләре, киекләр, кошлар йокламастан зикер-тәсбих әйткән бер вакытта минем изрәп йоклап ятуым ялкаулык булмасмы?» – диде.

*Унтугызынчы тәрбия.* Бик озак заманнар бер урманда үлән вә яфрак белән тәрбияләнеп тереклек кылучы бер заһид бар иде. Бер падишаһ ул заһидка зиярәт барды. Әйтте: «Я шәех, әгәр мәслихәт күрсәң, шәһәрдә тор, синең өчен урын хәзерлим, тыныч вә рәхәт гыйбадәт кылып ятыр идең», – диде. Дәхи дә синең бәрәкәтле

нәфесең белән файдаланыр идек. Вә һәм синең изге гамәлләреңә безләр дә иярер идек, диде. Заһид кабул итмәде. Әркян дәүләт падишаһка әйттеләр: «Мәслихәт шулдыр ки: берничә көннәргә ул заһидне шәһәргә китереп, бераз кунак итеп караек, сафа хатир белән бәлки торырга разый булыр», – диделәр. Бәс, мәзкүр заһидне шәһәргә чакырып китерделәр, бер сарайда үзенә хас бер урын хәзерләделәр. Вә бер мәкам[33] дилкәшә[34] хәзерләделәр ки, әгәр мәет керсә дә хәят табар. Падишаһ ул заһиднең хезмәтенә бер хуб руи[35] кәнизәк җибәрде, янә гүзәл сыйфат бер егет җибәрде. Аннан соң ул заһид ләззәтле локмәләрне тәнавел[36] кыйла башлады. Ләтыйф[37] вә йомшак киемнәрне кия башлады. Вә әнваг фәвакиһә белән, вә хуш исле мивәләр[38] белән тәрбияләнә башлады. Вә кәнизәкнең җәмаленә[39] тамаша кылып күз сала башлады... Бер вакытны падишаһ ул заһидне күрмәгә ирадә[40] кылды. Килеп күрде ки: заһидебез элгәреге заһидлек сыйфатыннан чыкмыш, куллары агармыш, йөзләре кызармыш, үзе вә нәфесе симермеш – җефәк мендәрләргә таянмыш, маһ пәйкәр[41] бер кәнизәк хезмәтенә тормыш, тависдай бер егет баш очында җилпәзә тотмыш. Падишаһ хәйран булды. Әйтте: «Бу ике таифәне, ягъни голяманы вә заһидләрне мин дуст тотадыр идем», – диде. Бер вәзир әйтте: «Әй падишаһым, голямага алтын бир, таки гайреләр һәм галим булырга рәгъбәт итсеннәр. Заһидләргә

---

[33] мәкам – урын
[34] дилкәш – күңелне үзенә тартучы
[35] хуб руи – гүзәл, күркәм йөзле
[36] тәнавел – авыз итү, татып карау
[37] ләтыйф – гүзәл, мөлаем, нәфис
[38] мивә – җиләк-җимеш
[39] җәмал – матурлык, гүзәллек
[40] ирадә – теләк, теләү
[41] маһ пәйкәр – ай йөзле

шундый нәрсә бир ки: урыннарында заһид булып калсыннар», – диде, ягъни ләззәти дөньядан алар хат[42] алмасыннар димәктер.

*Егерменче тәрбия.* Мисыр шәһәрендә ике әмирзадә бар иде. Берсе гыйлем өйрәнде, берсе мал җыйды, бай булды. Ул берсе голяма булды, бу берсе – финанс министры булды. Бәс, бу бай булганы галим булганына кимсетү күзе белән карар иде вә әйтер иде: «Мин солтанлыкка ирештем, син һаман бер ноктада торасың», – диде. Галим әйтте: «И туганым, Аллаһ Тәгаләгә шөкер итмәк минем тарафымдадыр, чөнки мин пәйгамбәр мирасын таптым, әмма син фиргавен мирасың алдың», – диде.

Әй угыл, бу кыйссадан сиңа тәрбия шулдыр ки: канәгать кирәк. Гыйлем, әлбәттә, пәйгамбәр мирасыдыр.

*Егерме беренче тәрбия.* Гаҗәм падишаһларыннан бер падишаһ бер оста табибны пәйгамбәр галәйһиссәлам хезмәтенә җибәрде. Ул табиб ничә еллар гарәб илләрендә торды. Һичбер кеше моңар: «Миңа дәва кыйл», – дип, янына килмәде. Бер көн ул табиб пәйгамбәр галәйһиссәлам янына килеп шикаять кыйлды. «Фәлән кадәр көннәр монда торамын, һичкем миңа илтифат кыйлган кеше юк», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Бу халыкның гадәтләре шулдыр ки: ашыйсылары килми торып – һич тәгам ашамаслар, вә тамаклары туймас борын тәгамнән кул тартырлар, ягъни тәгам туйганчы ашамаслар», – диде. Табиб әйтте: «Сыйхәтне булдырмак нәрсә шул лабаса», – дип, җир үпте дә китте. Инде, әй угыл, бу хикәят тәрбияңне җиткердеме? Инде корсагың тулганчы ашама, сыйхәттә булырсың, аз белән канәгать кыйл.

*Егерме икенче тәрбия.* Бер адәм гомерендә ничә мәртәбә тәүбә кыйлды, һаман тәүбәсен сындырды. Аксакаллардан берәүгә моны шикаять кыйлды: «Тәүбәмне тота алмыймын, гаҗизмән», – диде. Ул

[42] хат – юнәлеш

аксакал әйтте: «Мин шундый гөман кыйламын ки: син күп ашарга гадәтләнгәнсең, нәфесне җиңмәк бик читен эшдер. Син нәфесне тәрбия кыйлсаң, ул сине шундый зынҗырлар ки, бервакыт сине егар», – диде. Бәс, әй угыл, нәфсең симергән саен, ул сине һәлакәткә тартыр. Дөньяда баһадир шул кешедер ки: нәфесен җиңәр.

*Егерме өченче тәрбия.* Ишеттем ки, бер фәкыйрь дәрвиш ачлык утына көйгән, бер-берсе өстенә җамаган кием кигән... Дустларыннан берсе әйтте: «Ник утырасың? Ошбу шәһәрдә фәлән кеше бар, мохтаҗларның хаҗәтен үтидер. Әгәр синең дә халеңне белсә, халеңә шәфкать кыйлыр иде», – диде. Ул фәкыйрь әйтте: «Тик тор. Фәкыйрьлектә үлмәк, кешегә хаҗәт белән бармактан хәерлерәкдер», – диде.

*Егерме дүртенче тәрбия.* Хорасан вилаятендә ике дәрвиш бар иде, бер-беренә юлдаш булып сәфәргә чыктылар. Бере бик зәгыйфь иде, руза тотып ике көнгә бер мәртәбә авыз ачар иде. Бере куәтле иде, көн дә өч мәртәбә тәгам ашар иде. Бер шәһәргә керделәр. Ул шәһәрдә боларны, сез шымчыларсыздыр дип, тотып хакимнәренә илттеләр, бер ханәгә яптылар. Ике җомга тикшергәннән соң белделәр ки, гөнаһсыз адәмнәр, имеш. Чыгарып җибәрергә әмер булды. Зинданханәнең[43] ишеген ачып керделәр, күрделәр ки: куәтле дигәне җан тәслим кыйлмыш. Зәгыйфьне карадылар, зәгыйфь дигәне – җанын сәламәт асрамыш. Моңар бик гаҗәпкә калдылар. Бер хәким әйтте: «Әгәр моның хилафы вакыйг булган булса, гаҗәп булыр иде. Чөнки ул берсе – күп ашаучы икән, озак ачлыкка тәкать тота алмаган, үлгән. Әмма икенчесе – бер саклanучан адәм, имеш, үзен саклаган вә сабыр кыйлган, сәламәт калган», – диде. Әй угыл, нәфесен бик тәрбия кыйлган кеше катылыкка чыдамыйдыр.

[43] зинданханә – төрмә

*Егерме бишенче тәрбия.* Хәкимнәрдән бер адәм үзенең углын күп ашаудан тыйды. Әйтте: «Әй угыл, күп ашау кешене сырхау итәдер, күп ашама», – диде. Углы әйтте: «Әй ата, ачлык кешене үтерәдер, фәлән кеше ач үлгән диләр, күп ашап үлде дигәнне ишеткәнем юк». Атасы әйтте: «Алай да, углым, үлчәү белән ашамак кирәк. Күп ашау адәмне үтермәсә дә, күп яхшылык та күрмәйдер. Вә исраф буладыр, исраф хәрамдыр», – диде. Бу кыйссадан сиңа бер тәрбия хасил булсын ки, китап әйткән сүзне күңелеңә сеңдер.

*Егерме алтынчы тәрбия.* Бер фәкыйрь бер вакытны бик мохтаҗ булып калды. Дусларыннан берсе әйтте: «Фәлән кеше бик бай вә нигъмәт иясе адәмдер, әгәр синең мохтаҗ икәнеңне белсә, шаять шәфкать кылыр», – диде. Бу фәкыйрь әйтте: «Бәлки шулай булыр иде, әмма мин аны белмим», – диде. Ул кеше әйтте: «Әйдә, мин үзем күрсәтәм аны сиңа, – диде. Бергә бардылар. Бу фәкыйрь барып җиткәч, ишегалдында берәүне күрде: иреннәре салынган, күңелсез вә хафа утырыр. Бу фәкыйрь бер сүз әйтмичә кайтып китте.

*Егерме җиденче тәрбия.* Муса галәйһиссәлам бер фәкыйрьне күрде: ялангач, киеме юклыктан комга кереп яткан. Әйтте: «Я Муса, дога кыл, Аллаһе Тәгалә миңа байлык бирсен, фәкыйрьлеккә такатем[44] калмады», – диде. Бәс, Муса галәйһиссәлам дога кылды. Аз заманда Аллаһе Тәгалә аны бай кылды. Муса галәйһиссәлам берничә заманнан соң аны янә күрде. Бер җирдә халык күп җыелган. Муса галәйһиссәлам сорады: «Ни хәл булды?» – диде. Әйттеләр: «Бу фәлән кеше хәмер эчеп исергән, сугышкан, бер кешене үтергән. Халән[45] аны кыйсас кылалар[46]», – диделәр. Муса галәйһиссәлам Аллаһе Тәгаләнең хикмәтенә икърар кылып: «Баксәнә, ашыгып дога

[44] такать – көч, чыдамлык
[45] халән – хәзер
[46] кыйсас кылу – җәза бирү

кылдым», – дип үкенде вә истигъфар[47] кылды... Әй угыл, Аллаһе Тәгаләнең хикмәте бар: берәү бай, берәү фәкыйрь, әмма бай булмак, фәкыйрь булмак адәмнең үз фигыленнән түгелдер. Канәгать кирәк.

*Егерме сигезенче тәрбия.* Шәех Сәгъди хикаять кылмыштыр ки: «Замананың инкыйлябыннан[48] һәнүз еглаганым вә шикаять кылганым юк иде. Мәгәр бер вакытны аягыма кияргә юк иде, аякларым ялангач, Күфә мәсҗеденә килдем. Бер аяксызны күрдем, вә Аллаһе Тәгаләгә шөкер вә сәна кылдым, вә аягым ялангачлыгына сабыр кылдым», – диде. Имде, әй угыл, бу кыйссадан сиңа бераз тәрбия бирәм.

*Егерме тугызынчы тәрбия.* Бер бик зәгыйфь балыкчының кармагына бик куәтле олуг балык эләкте. Ул балыкны тартып чыгарырга балыкчының куәте җитмәде. Балык кармакны өзеп качты. Икенче балыкчылар моны күреп мәлямәт[49] вә шелтә кылдылар: «Кармагыңа мондаен кыйммәтле балык эләккән иде, ычкындырдың, һай начар», – диделәр. Балыкчы әйтте: «Әй егетләр, миңа насыйп булмаса, мин ничек итим, дәхи балыкның көне бетмәсә, мин ни кылыйм», – диде. Балыкчы насыйп булмаган балыкны тоталмый. Балыкның әҗәле җитмәсә, кармакка керә алмый. Шулай инде, халык арасында гел фәкыйрь шелтәгә тарый.

*Утызынчы тәрбия.* Бер сәүдәгәр үзенең сәүдәсендә мең алтын зарар итте вә углына әйтте: «Әй угыл, бу серне кешегә әйтергә кирәкмәс», – диде. Углы әйтте: «Әй ата, фәрман сәнеңдер. Вә ләкин бу серне яшерүдән безгә ни файда булыр?» Атасы әйтте: «Таки ике кайгы булмасын дип әйтәмен ки, бер кайгы – сәрмаябыз[50] кимүе,

[47] истигъфар – гафу үтенү, ярлыкауны сорау
[48] инкыйляб – алмашу, үзгәрү
[49] мәлямәт – шелтә, орышу
[50] сәрмая – капитал, акча

икенче кайгы – күршеләребезнең шәматәсе[51]», – диде. Әй угыл, шәматә дигән нәрсә мәзмүм[52] холыктыр, шәматәдән саклан, ягъни берәүнең кайгысын яки зарарын күреп, яки ишетеп сөенмәкне шәматә диерләр.

*Утыз беренче тәрбия.* Гакыл иясе вә фазыйләтле[53] бер егет бар иде. Әмма ничә мәртәбә галимнәр вә данишмәндләр[54] арасында утырыр, бер сүз сөйләмәс иде. Атасы әйтте: «Әй угылым, белгәнеңне ник сөйләмисең? – диде. Углы әйтте: «Куркамын ки, әгәр белгәнемне кешегә белдерсәм, галим икән дип, минем белмәгән нәрсәмне сорарлар да оятлы булырмын», – диде. Әй угыл, хикәяттән сиңа файда шулдыр ки: бернәрсәне тәмам көнһенә[55] ирешеп белмәсәң, телеңә китермә.

*Утыз өченче тәрбия.* Бер падишаһ үзенең углын остазга гыйлем укымага бирде. Остаз күп иҗтиһад белән падишаһның углына тәгълим бирде, вә яман нәрсәләрдән мәнгы кылды[56], вә кайчак кыйнады. Бу бала тәкатьсезлегеннән атасына кайтып шикаять кылды, тәнен ачып күрсәтте. Атасы моңар хафаланып остазны чакыртты, әйтте: «Әй остаз, гавам[57] балаларын бу кадәр җәфа кылмыйсың икән, безнең балабызга бу кадәр җәфа вә җәбер күрсәтәсең, ни сәбәптер? – диде. Остаз әйтте: «Әй падишаһ, аның өчен ки, гавам балаларына игътибар юктыр, әмма падишаһ балалары җәфа ни нәрсә, җәбер ни нәрсә икәнен белеп үссеннәр. Таки падишаһ булганнан соң, җәбер вә золым ни икәнен белеп, саклансын. Әгәр падишаһтан вә падишаһ балаларыннан җәбер вә

---

[51] шәматә – кеше кайгысына сөенү
[52] мәзмүм – начар, хурланган
[53] фазыйләтле – белемле, мәгърифәтле
[54] данишмәнд – белгеч, галим, белем иясе
[55] көнһ – бер әйбернең нигезе, төбе, асылы
[56] мәнгы кылу – тыю, рөхсәт бирмәү
[57] гавам – халык, кара халык

золым садир булса[58], илдән илгә йөртерләр». Вә кәзалик[59] олуг кешеләрнең вә байларның балаларын тәрбия вә тәртип бирүдә гавам балаларыннан артыграк карарга тиеш, ягъни мәзһәбне[60] киңәйтмичә, тыгызрак тотып, тәрбия кылырга тиеш, бай дип, иркенлек кылырга ярамый.

*Утыз дүртенче тәрбия.* Әй угыл, балаларга тәгълим бирсәң, кечерәк вакытта бик иҗтиһад кыл. «Әл-гыйльме фи с-сәгүри кәнәкаши фи л-хәҗәри»[61] мазмунынча чыбыкны нечкәрәк чагында бөгү сәһелрәккә киләдер. Кечерәк вакытта күп фәннәргә төшендермәк кирәк, гыйлем риязияттән[62] аз-аз белдермәк тиеш. Әмма бу балаларга сабак укыту хосусында сиңа яхшырак тәрбия бирәсем бар.

*Утыз бишенче тәрбия.* Бер падишаһ углын бер остазга бирде, әйтте: «Әй остаз, бу бала синеңдер, үз низамынча яхшы тәгълим биргәйсең», – диде. Бәс, остаз бу падишаһ баласына башка балалар кыйтарәсендә иҗтиһад белән тәгълим бирде. Ләкин падишаһ баласы гавам балалары җиткән дәрәҗәгә җитмәде. Бәс, падишаһ җәза кылмакчы булды. Остаз әйтте: «Әй падишаһ, тәрбия бердер, ләкин истигъдад[63] башкадыр», – диде. Бәс, әй угыл, гавам балалары күбрәк бай балаларыннан чабегрәк[64] вә зирәгрәккә киләдер. Мин сиңа шуның өчен әйтәмен: бай балаларына артыграк иҗтиһад сарыф кылмак кирәк, алар бик иркә булалар.

---

[58] садир булу – башлану, барлыкка килү
[59] кәзалик – шуның кебек
[60] мәзһәб – бара торган юл
[61] «Яшь чакта алган гыйлем ташка чокып ясалган бизәккә охшаш»
[62] риязият – математика
[63] истигъдад – сәләтлелек, зирәклек, үткенлек
[64] чабек – өлгер, җитез

*Утыз алтынчы тәрбия.* Бер гарәп үзенең углына әйтте: «Бак, угыл, кыямәт көнендә синнән: «Син кем углы дип сорамаслар, бәлки ни гамәл китерден?» дип сорарлар», – диде.

*Утыз җиденче тәрбия.* Шәех Сәгъди риваять кылмыштыр ки, бер фәкыйрь адәм бар иде, гомерендә бала күрмәде, Аллаһе Тәгаләдән сорады: «Әгәр углым булса, ошбу өстемдәге хиркамыннан[65] башка милкемдә нәрсә юктыр, аны сатып фәкыйрь-фокарага өләшер идем», – дип нәзер кылды. Аллаһе Тәгалә аңа бер угыл рузи кылды. Бик шатланып, әйткән нәзерен үтәде, фәкыйрьләргә ингам-ихсан кылды[66]. Берничә елдан, янә Шам сәфәреннән кайтканда, юлым шул шәһәргә тугры килеп, ул кешене сораштым. Әйттеләр, зиндандадыр. «Ни сәбәпле зинданга төште?» – дип сорадым. «Углы бер вакытны хәмер эчеп сугышып, бер адәмне үтергән иде, һәм шәһәрдән качкан иде. Углын тапмагач, углы урынына атасын зинданга салдылар».

Әй угыл, ошбу заманабызда да моңар охшашлы вакыйгалар бардыр ки, ниндәен байлар бар, балалары яшь вә кечкенә заманда, кырык-илле мең, йөз мең белән сәүдә кылучылар бар. Балалары үсеп җиткәч, фәкыйрь вә мохтаҗлыкка калалар. Ул нидәндер? Әлбәттә, кечкенә вакытта балаларын яхшы тәрбия кыла белмәгәнлектәндер.

*Утыз сигезенче тәрбия.* Бер галим әйтте: «Һәрбер дошман ки, ихсан кылсаң, дуст тотадыр, мәгәр нәфес ки, морадын[67] никадәр бирсәң, шулкадәр зиядәне[68] эстәйдер», – диде.

*Утыз тугызынчы тәрбия.* Хикмәт мал дигән нәрсә – гомерне тынычлык белән кичермәк өчендер; түгелдер ки, фәкать мал җыймак өчең. Бер гакыл иясеннән сорадылар. «Изге бәхетле кемдер, дәхи

---

[65] хирка – дәрвишләрнең өс киеме
[66] ингам-ихсан кылу – ярдәм, булышлык, изгелек итү
[67] морад – теләк, теләнгән әйбер
[68] зиядә – артык, артыграк

явыз бәхетле кемдер?» – диделәр. Ул кеше әйтте: «Изге рәхәтлелекнең галәмәте шулдыр ки: дөньяда сакланучан булыр, ахирәтне онытмас, гыйбадәтчән булыр... аз сүзле булыр... хәрамнан сакланыр, изгеләргә мәхәббәт итәр, кече күңелле булыр, юмарт булыр, шәфкатьле булыр. Әмма явыз бәхетле шулдыр ки, мал җыярга хирыс булыр, нәфесенә иярер, күп сөйләшер... явызларны яратып, явыз холыклы булыр, хәйләкәр булыр, шәфкатьсез булыр, саран булыр, үлемне онытыр».

Әй угыл, бу урында сиңа яхшы бер тәрбия бардыр ки, изге бәхетле бул, явыз бәхеттән саклан, монда сиңа изге бәхет галәмәтләрен санап китерүдән максуд: сине изге бәхетле кыйлмактыр.

*Кырыгынчы тәрбия.* Муса галәйһессәлам Карунга мондый нәсихәт бирде: «Аллаһ Тәгалә сиңа ихсан кылды – сине бай итте. Инде син дә ихсан һәм изгелек кыл»,— диде. Карун Мусаның сүзен тыңламады. Малы-мөлкәте белән аны җир йотты. Әй угыл, берәү сиңа изге нәсихәт кылса, җаның-тәнең белән аны тыңла – ул өйрәткәнчә гамәл кыл.

*Кырык беренче тәрбия.* Әй угыл, ике төрле таифә бардыр ки, файдасызга вә мәгънәсезгә зәхмәт чигәрләр. Бере шулдыр ки: акча вә мал җыяр, үзе файдаланмас. Янә бере шул галимдер ки: гыйлем өйрәнде, гамәл кыйлмады. Бу ике таифә җөмләсеннән була күрмә, әй угыл.

*Кырык икенче тәрбия.* Һәрбер сереңне дустыңа әйтмә, чөнки кайдан беләсең, бервакытны дошман булып китәр. Дошманыңа, кулыңнан килсә, зарар итмә, бәлки бервакытны, үзеңә дус булыр. Дустыңның дустына да ышаныч юк, аң бул. Әмма ике дошман арасында сүз сөйләсәң, белеп сөйлә: әгәр дуслансалар, үзеңә оят килмәсен.

*Кырык өченче тәрбия.* Дустың белән сөйләшкәндә акрын сөйләш, сөйләшкән сүзең дошманыңа ирешмәсен. Хәтта бер дивар янында сөйләсәң дә, гакыл белән сөйләш, таки дивар артында колак булмасын. Әмма дошманның нәсихәтен кабул итмәк хатадыр. Ләкин ишетмәкнең гаебе юк, чөнки гыйбрәт алып гамәл кыласың.

*Кырык дүртенче тәрбия.* Куәте барында изге гамәл кыйлмаган кеше зәгыйфь вакытында катылык күрер.

*Кырык бишенче тәрбия.* Әй угыл, җиде төрле кешегә киңәш итмә. Әүвәл, надан кешегә киңәш итмә, чөнки надан кеше, үзенең наданлыгына булышып, сине азгынлык юлына салыр. Икенче, дошманыңа киңәш итмә, чөнки дошман кеше сине һәлакәткә тартыр. Өченче, хасидкә вә көнче кешегә киңәш итмә, чөнки көнче кеше синең нигъмәтеңә зыян килүен теләр. Дүртенче, икейөзле кешегә киңәш итмә. Чөнки ул кеше һәркайчан адәмнең ризалыгын гына карап торыр. Бишенче, куркак кешегә киңәш итмә, чөнки куркак кеше сиңа һичбер мәслихәт бирергә җөрьәт кыйлмас. Алтынчы, саран кешегә киңәш итмә, чөнки саран кеше мал җыярга хирысдыр, анда дөрес киңәш юктыр. Җиденче, малга комсыз кешегә киңәш итмә, чөнки нәфес арзуына ияргән кеше нәфесенә каршылык кыйла алмас.

*Кырык алтынчы тәрбия.* Халыкка икмәк-тоз күрсәтмәгән кешенең үлгәч тә исемен телгә алмаслар. Тереклеге белән сөендермәгән кешенең үлеменә дә бик кайгырмаслар.

*Кырык сигезенче тәрбия.* Әй угыл, үзеңнең сихәтеңә[69] вә үткән көннең сәламәтлегенә мәгърур булма[70] вә алданма. Чөнки гомереңнең мөддәте[71] аздыр, даимән сихәттә булмагың мөхальдер[72].

[69] сихәт – исәнлек, сәламәтлек
[70] мәгърур булу – масаю, горурлану
[71] мөддәт – вакыт
[72] мөхаль – булмый торган, мөмкин булмаган

Бәс, сихәтнең кадерен бел, үзеңне хайван дәрәҗәсеннән чыгар. Ләкин хифыз сихәтнең[73] шартлары күптер.

*Кырык тугызынчы тәрбия.* Әй угыл, чәчкәнеңне урырсың, кылганыңны күрерсең, ягъни изге эш кылсаң, гыйкаб-газапка[74] мөстәхикъ булырсың.

*Илленче тәрбия.* Әй угыл, саран кеше фәкать үз малының каравылчысыдыр вә варисларының хәзинәчеседер, ягъни үзенең малына бары каравыл тора вә варисларына тапшырмак өчен бары вакытын көтәдер. Бу хикмәтләрнең гарәпчәсе «Фәвакиһелҗөләса»дә[75].

*Илле беренче тәрбия.* Әй угыл, әхлак сәйеә иясенә[76] вә явыз холыклы кемсәнәгә әфгаль хәсәнәңне вә изге холыкларыңны күрсәтмәк белән вәгазь вә нәсихәт кыл, телең белән нәсихәт кылганчы, фигылең белән нәсихәт кыл димәктер. Шаять ки, бу сүзне бәян кылмасам да, фәһем итсәң кирәк.

*Илле икенче тәрбия.* Әй угыл, яхшылыкның кадерен белмәгән кешедән ерак булган яхшы. Берәүгә бер яхшылыгың тисә, миннәт[77] итмә, берәүдән яхшылык күрсәң, фаш кыл, онытма.

*Илле өченче тәрбия.* Әй угыл, һәрникадәр җисмеңдә сихәт вә затыңда яшьлек вә егетлек булса да, тәүбәсез вә васыятьсез ятып йоклама. Адәмнең әҗәле күз белән каш арасындадыр.

*Илле дүртенче тәрбия.* Әй угыл, күршеләрен хур вә зәлил[78] тоткан кеше газиз вә хөрмәтле булмас. Вә карендәшләрен мәхрүм

[73] хифыз сихәтнең – сихәтне, исәнлекне саклауның
[74] гыйкаб – җәза, газап
[75] Каюм Насыйриның хезмәте
[76] әхлак сәйеә иясе – әхлагы начар кеше
[77] миннәт – берәүгә иткән яхшылыкны һаман искә төшереп сөйләү
[78] хур вә зәлил – игътибарсыз, кадерсез

куйган кеше малының рәхәтен табалмас. Саф күңелле вә күркәм фигыльле булган кешене ригаять[79] вә ихтирам кылмак важибдер[80].

*Илле бишенче тәрбия.* Әй угыл, бер кеше сине явыз холкы белән рәнҗетсә, хилемең[81] белән аңа вәгазь кыл, ягъни аннан интикам[82] алаем дип мәшәкать чикмә... Интикам вә мөҗазатка[83] кадәр була торып гафу кылмак – җәмигъ изге холыкларның күркәмрәгедер.

*Илле алтынчы тәрбия.* Мохтаҗ адәмнәрнең дә ингам вә ихсанга мөстәхикъръәге[84] вә бирергә тиешлерәге сөальдә пәрһизрәгедер[85], ягъни берәүнең мохтаҗ икәнен беләсең икән, вә һәм миннән хаҗәт теләр дип тә гөманың[86] бар икән, үзе сорамас борын, тизрәк бирә күр.

*Илле җиденче тәрбия.* Әй угыл, берәүгә иткән ингам вә ихсаныңны вә аңар иткән яхшылыгыңны әйтеп: «Мин сиңа фәлән яхшылыклар кылдым», – дип миннәт итсәң, адәм тарафыннан рәхмәт вә Аллаһы Тәгалә тарафыннан савап өмет итмә. Син миннәт итмәсәң дә, ул кеше үзе дә белә вә Аллаһы Тәгалә дә синең кылган изгелегеңне беләдер.

*Илле сигезенче тәрбия.* Әй угыл, тар холыклы кешенең ризыгы да тар була, имеш. Киң холыклы вә сабырлы булырга тиеш. Тугры сүзле кешенең җәмалы артык булыр, ягъни сүзендә вә фигылендә тугры кешегә халык мәхәббәт итәдер...

---

[79] ригаять – олылау, игътибар итү, хөрмәтләү
[80] важибдер – үтәлергә тиешле дини эш
[81] хилем – йомшаклык, ачусызлык
[82] интикам – үч алу, ачу кайтару
[83] мөҗазат – җәзалау, җәза
[84] мөстәхикъ – мохтаҗ
[85] сөальдә пәрһизрәге – сораудан сакланучы
[86] гөман – уй

*Илле тугызынчы тәрбия.* Хәерле мал шулдыр ки: хәлялдән килер, изге юлга сарыф кылыныр. Вә хәерсез мал шулдыр ки: хәрамнан килеп, фисык[87] вә фәсад[88] юлына сарыф кылыныр... Хәлялдән килгән акча асла[89] хәрамга китмәс һәм ул мал иясендә карар кылыр[90], үлгәнче ул кеше дәүләттән чыкмас. Вә хәрамнан килгән мал иясенә йокмыйдыр. Ул хәрамнан килгән, имеш, янә хәрамга китә-китә китеп бетәдер, китә башласа, иясе дә аны туктата алмыйдыр, тиз заман мохтаҗ булып каладыр.

*Алтмышынчы тәрбия.* Әй угыл, агяһ бул[91] ки, сиңа изгелек кылган кешегә яманлык кылма, вә сиңа нигъмәт биргән кешегә иһанәт[92] кылма, вә хәкарәт нәзары[93] белән карама. Залимлыгы күп булган кеше тиз һәлак буладыр вә һәм дошманнары күп буладыр. Залимлыктан зиядә сакланмак кирәк.

*Алтмыш беренче тәрбия.* Залимнарга носрәт[94] вә ярдәм бирүче кеше – залимнарның берседер вә адәмиләрнең явызрагыдыр. Әмма, әй угыл, залимлык дигән нәрсә акча вә гайре нәрсә хакында гына түгел, бәлки сүздә вә фигыльдә һәм залимлык буладыр.

*Алтмыш икенче тәрбия.* Халык арасында берәүне вәгазь вә нәсихәт кылмак аны башына сукмак кебектер. Һичшиксез, ул кеше сиңа дошман булды. Ул синең нәсихәтеңне тоту кая, хәтта синең һәлякеңә[95] тарикъ эзләр. Халыкка сыпыйлыгыңны[96] күрсәткән булып, булыр-булмас җирдә нәсихәт кылган булып маташма.

---

[87] фисык – начарлык
[88] фәсад – бозыклык, әшәке эш
[89] асла – һич тә
[90] карар кылу – бер урында тору, даимилек, урынлашу
[91] агяһ бул – белеп тор, хәбәрдар бул
[92] иһанәт – кимсетү, хурлау
[93] хәкарәт нәзары – кимсетү карашы
[94] носрәт – ярдәм, өстенлек
[95] һәляк – бетү, үлү
[96] сыпыйлык – суфилык

*Алтмыш өченче тәрбия.* Әй угыл, карендәшләрчә мәгашәрәт[97] кыл, ятларча мөгамәлә кыл, ягъни алышта-бирештә бу карендәш кеше дип ригаять кылма. Вә дәхи алышта-бирештә: «Мин карендәш кеше ләбаса, азрак ригаять кыл», – димә, чөнки мал башка, карендәшлек башка. Бу хосуста ригаять кылышу гадавәт[98] вә дошманлыкка мөәдди[99] буладыр...

*Алтмыш дүртенче тәрбия.* Тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачырактыр вә яманрактыр, ягъни телдән садир булган[100] ачы вә кабахәт сүзләрнең адәмгә әсәре тәнеңне пычкы белән кискәннән дә ачырактыр. Әй угыл, һичбер кешегә телең белән җәрәхәт салма, ягъни яман сүз әйтмә. Адәмнең җанына тия торган сүз әйтмә. Әмма бер сүзне син сәһелгә хисаплап әйтерсең дә, кешенең күңеленә бик каты тияр. Әй угыл, каты сүзле булма. Изге холык белән вә йомшаклык белән татлы сүзләр сөйләшмәк ризыкның ачкычыдыр, димешләр. Яхшы вә йомшак сүзгә адәмнең күңеле эреп китәдер. Кешегә ашыгып сүз әйтсәң вә ашыгып җавап бирсәң, һичбер хата сүз садир булмаенча булмас.

*Алтмыш бишенче тәрбия.* Һәр эшнең ахырын фикер кылып вә уйлап эш кылган кеше бәла вә кайгыдан имин булыр. Вә сәламәт калыр. Уйламаенча, ашыгып эш кылган кеше һичбер нәдамәт[101] вә үкенеч тартмай калмас.

*Алтмыш алтынчы тәрбия.* Әй угыл, бер җиргә керсәң, әүвәл ничек итеп чыгасыңны уйламак кирәк... Бер ишекне ачсаң, ничек итеп ябармын дип уйламак кирәк. Ягъни бурычка керсәң, ничек итеп түләрмен дип, әүвәл түләвеңне искә төшер. Вә дәхи бер эшкә

[97] мәгашәрәт – аралашу
[98] гадавәт – ачу саклау, нәфрәт
[99] мөәдди – сәбәпче, алып баручы
[100] садир булу – барлыкка килү
[101] нәдамәт – үкенү, тәүбә

шөругъ кылсаң[102], ничек итеп тәмам кылырмын дип, тәмам кыласыңны искә төшер.

*Алтмыш җиденче тәрбия.* Ялганчылык белән мәгъруф булган[103] кеше һәрникадәр тугры сүз әйтсә дә, төһмәтледер[104]. Бер мәртәбә ялганчылыгың сизелсә, һич сүзеңә дә ышанмас булырлар...

*Алтмыш сигезенче тәрбия.* Әгәр зәбун[105] вә пәст[106] кемсәнәләр вә җаһилләр[107] олуглар дәрәҗәсенә ирешсәләр, олуглар вә фазыйлле[108] адәмнәр һәлак дәрәҗәсенә төшәрләр, ягъни фазыйләтле адәмнәрнең кадере калмас. Әй угыл, яман холыклы вә тар холыклы кемсәнәләрдән кач вә ерак кит, күркәм холыклы кемсәнәләрдән аерылма вә әхлагы хәмидә белән монсыйф бул.

*Алтмыш тугызынчы тәрбия.* Әй угыл, әйткән сүз аткан ук кебектер. Һәрбер сүзне уйлап сөйләшергә кирәк, авызыңнан чыккан кире кайтмас. Гөнаһлы була торып та тәүбәгә ашыкмаган кеше гөнаһысы, сагыйрә[109] булса да, кәбирәгә[110] әйләнәдер.

*Җитмешенче тәрбия.* Тәдбир белән тотсаң вә сарыф кылсаң, аз нәрсә дә бәрәкәтле буладыр, вә тәдбирсез тотып исраф кылсаң, күп нәрсә дә җитмидер... Әй угыл, гакыллы кеше шулдыр ки: кулындагын саклар, бүгенге эшен иртәгә калдырмас.

*Җитмеш беренче тәрбия.* Гыйzzәтлелек вә олуглык һиммәт[111] беләндер, чергүче туфрак белән иңмәстер, ягъни озын буй вә олуг сакал, вә җуан корсак белән түгелдер. Болар барысы да череп туфрак

---

[102] шөругъ кылу – керешү
[103] мәгъруф булу – танылу
[104] төһмәтле – шикле
[105] зәбун – вак, хурлыклы
[106] пәст – түбән
[107] җаһил – надан, белемсез
[108] фазыйль – яхшы холыклы, инсафлы, кешелекле
[109] сагыйрь – кечкенә
[110] кәбир – зур
[111] һиммәт – тырышлык

буласы нәрсәдер, олуглыкка дәлаләт кыла торган[112] нәрсә түгелдер. Һимметтән вә мәкярим[113] әхлактан ялангач булып та, буй белән вә җәмал белән, вә кыяфәт белән олуглыкны эстәмәк гаять ахмаклыктыр. Вә дәхи олуглык вә фазыйләт дигән нәрсә гыйлем вә әдәп беләндер вә мәкярим әхлак беләндер. Югыйсә күл өстендә яхшы атлар юргалату бер дә олуглыкка вә фазыйләткә дәлаләт кылмайдыр. Әй угыл, адәм булаем дисәң, мондаен юк эшләргә ихлас куйма.

*Җитмеш икенче тәрбия.* Гакыл ияләре белән вә гыйлем әһле белән мәгашәрәт вә мосахәбәт кылмак күңелләрне тергезер. Вә гыйлем вә мәгърифәт әһле белән мосахәбәт кылмак гатыр[114] сатучылар янында тормак белән бәрабәрдер ки, гәрчә сиңа ул гатыр бирмәсә дә, хуш исе борыныңа керәдер. Наданнар вә явызлар белән мосахәбәт кылмак тимерчеләр янында тормак белән бәрабәрдер: очкыннары сиңа килеп сачрар. Кәзалик наданның наданлыгы әсәр итәдер. Әй угыл, мөэмин карендәшеңдә булган гаепне мөмкин кадәр яшерергә тырыш, хосусән[115] ки, ул гаеп үзеңдә дә булса.

*Җитмеш өченче тәрбия.* Әй угыл, кешенең эшендә яки сүзендә хата күрсәң: «Һай, хата кылдың, болай кирәк», – дип хатасын төзәтмә, зирә ки синнән гыйлем һәм алыр, сине дошман һәм тотар. Бу эш үз башыма күп килгәне бар, вә ничә мәртәбә кешенең хатасын өйрәтеп үкенгәнем бар.

*Җитмеш дүртенче тәрбия.* Адәмнең табигате шулайдыр ки: мәнфагатен күргән кешегә мәхәббәт, вә зарарын күргән кешегә гадавәт итәр[116]. Әй угыл, кешегә мәнфәгать итәргә кулыңнан килми

---

[112] дәлаләт кыла торган – илтә торган, юл күрсәтә торган
[113] мәкярим – мактаулы, күркәм
[114] гатыр – ислемай, хушбуй
[115] хосусән – бигрәк тә
[116] гадавәт итү – дошманлык, ачу итү

икән, бары зарарыңны ирештермә. Ачык йөзле, татлы сүзле бул, дустың күп булыр.

*Җитмеш бишенче тәрбия.* Әмма әй угыл, мал кәсеп кылуның тарикы бик күптер. Ни тарикъ белән булса да, хәлялдән кәсеп кылмак фарыздыр. Хәлялдән килгән мал бәкальрәк буладыр. Хәрам мал адәмгә йокмыйдыр, тиз кулыңнан китәр, әмма вәбале[117] сиңа калыр. Әмма хәлялдән кәсеп иткән малыңны саклап тот, хәрам җиргә сарыф итмә. Малны сакламак малны җыймактан мөшкелрәктер. Саклап тота белмәгәнлек сәбәпле ни бай кемсәнәләр дәүләттән мәхрүм калдылар.

*Җитмеш алтынчы тәрбия.* Әй угыл, малның килүенә карап хәраҗатеңне тот, килүенә караганда хәраҗатең кимрәк булсын, дөньяда һич мохтаҗ булмассың. Һәр көн күпме-азмы хәраҗатеңнән артканы сәрмаяңа кушылсын, дәүләтең һаман артыр. Имде малың күп булган тәкъдирдә, фәкыйрь вакытыңны онытма. Ягъни фәкыйрь вакытыңда: «Бу нәрсә бу көнгә җитсен», – дип сарыф кыладыр идең, бай булгач, кәзалик хисап белән тот. Хәраҗатен үлчәү белән тоткан кеше мохтаҗ булмыйдыр.

*Җитмеш җиденче тәрбия.* Вә әгәр бер дустың яки карендәшең малын яки хезмәтен сиңа тапшырса вә әманәт[118] итсә, үз малың кебек итеп сакла, вә үз хезмәтең кебек итеп әда кыл. Ул сәбәпле Аллаһе Тәгалә синең малыңа бәрәкәт бирер вә халык арасында әманәт дарлык белән мәшһүр булырсың. Әмма, әй угыл, малыңнан бер нәрсәне бер кешегә әманәт куям дисәң, мөсриф[119] адәмгә әманәт куйма. Дәхи комарбазга[120], ягъни отыш уен уйнаучы кешегә вә хәмер эчкүчегә әманәт куйма.

[117] вәбал – гөнаһ, язык, авырлык
[118] әманәт – сакларга бирелгән әйбер
[119] мөсриф – әрәм-шәрәм итүче, исраф итүче,
[120] комарбаз –отыш уенын бирелеп уйнаучы

*Җитмеш сигезенче тәрбия.* Вә дәхи, әй угыл, бурыч итәргә һәвәс итмә. Вә файда белән алма, вә рәһен[121] белән акча алма, чөнки бу эшләр адәмне хурлыкка төшерер, чөнки кемгә бурычлы булсаң, аңар кол булырсың. Вә дәхи кешегә бурычка акча бирмә, хосусән дустыңа бирмә. Чөнки дустың вакытында үзе белеп бирмәсә, тәкрар[122] сорамак лязим килер, сорасаң, рәнҗер, арагызда дуслык бетәр. Дустыңны дошман итмәк җаһилләр эшедер.

*Җитмеш тугызынчы тәрбия.* Әй угыл, әгәр бер кеше сиңа әманәт куймак теләсә, кабул итмә вә үзеңә бәла йөкләмә. Чөнки әманәт сакламак бер бәладер, өч хәлдән хали[123] түгелдер. Бере будыр ки: әманәт нәрсәне үз малыңнан артыграк итеп сакламак белән зәхмәт[124] чигәрсең вә иясенә тапшырырсың. Яки тамгы кылып[125], синнән әманәт алганым юк дип инкяр кылырсың. Яки ул әманәт заегъ[126] булыр, ихтималдыр аннан соң оятка калырсың. Каза ирешеп заегъ булды дисәң дә, ышынмас. Бәс[127] әманәт сакламак сәһел эш түгелдер. Әмма әгәр дә әманәтне кабул итсәң, яхшы сакла вә хыянәт итмә. Вә әгәр берәү үзеңә сатарга бер нәрсә әманәт куйса, сатканнан соң тәвәкъкыфсыз[128] акчасын иясенә тапшыр. Әмма моны да әда кыла[129] алмасаң, әманәт итеп алма...

*Сиксәненче тәрбия.* Һөнәрле кол үлмәс. Әй угыл, һөнәрең кайсы булса да, үзең яхшы булсаң, акча китерәдер. Әмма һөнәрләрнең яхшысы, әгәр дә азрак сәрмаяң булса, сәүдә кылмак яхшы кәсептер.

[121] рәһен – заклад, закладка салу
[122] тәкрар – кабат, кабатлау
[123] хали – буш, азат
[124] зәхмәт – борчу, мәшәкать
[125] тамгы кылу – кешедә булган әйберне үзеңә алырга теләү, һаман кешедән өмет итү
[126] заегъ – югалган, юкка чыккан, һәлак булган
[127] бәс – димәк
[128] тәвәкъкыфсыз – тоткарлыксыз
[129] әда кылу – үтәү

Ләкин хәлял сәүдә кылмак бик читен эштер. Әмма иҗтиһад кыл, әй угыл, хәлялдән сату ит. Хәлял сәүдә белән хасил иткән бер тиенең ун тиен хәрамыңны бәреп егар. Сәүдә малы алсаң, малның яхшысын ал, чөнки яхшы нәрсәдән файда өмете бардыр, начар нәрсәң сатылмый калса, зарар булыр.

*Сиксән беренче тәрбия.* Вә дәхи, әй угыл, адәм вә һайван ризыгы булган нәрсә белән алу-сату итмә. Ягъни икмәк-ашлыкны арзан вакытта алып, кыйммәтләнгәч, яки ачлык вә кахт[130] елда сатармын дип ашлыкны җыеп асрамак хәрамдер, моны ихтикяр[131] диерләр. Вә дәхи, әй угыл, сату-алуда ялган сөйләшмә вә ант итмә. Әмма сату-алуны җиңел кыл. Әмма кешегә шәрик[132] булып сәүдә кылудан саклан, чөнки дөньяда гадел кеше аздыр, низагътан башын чыкмас. Сынамаган вә тәҗрибә кылмаган мал белән сату итмә, үзеңнең өйрәнгән сәүдәңне ташлама.

*Сиксән икенче тәрбия.* Әй угыл, «Гәдүүе гакыйл хәер мин садыйки җаһий»[133]. Ахмак вә надан адәм дуслыкка вә дошманлыкка һәм ярамас. Вә һөнәрсез кеше дуслыкка ярамас. Саклан шул кешедән ки, үзе бернәрсә белмәс, үзен галим вә белекле санар. Бер эшне бер мәртәбә эшләп тугры килмәсә, икенче мәртәбә ул эшкә тотынма, вә кулыңнан килмәгән эшкә тотынма.

*Сиксән өченче тәрбия.* Әй угыл, гәрчә тугры сәйләмәк ачыдыр, әмма тугры сөйлә. Әгәр дошман серемне белмәсен дисәң, дустыңа да сереңне әйтмә, таки дошманыңа барып әйтмәсен. Олугларны олуг ит, кечеләргә шәфкатьле бул. Надан вә һөнәрсез кешеләрне терекә сайма, мәет дип бел. Бер эшне ике мәртәбә эшләмә.

---

[130] кахт – яңгырсызлык, корылык
[131] ихтикяр – спекуляция
[132] шәрик – иптәш, катнашучы, бер эшне бергәләп алып баручы
[133] Акыллы дошман надан дустан яхшырак.

*Сиксән дүртенче тәрбия.* Эшлексез кешенең икмәген ашаудан ач тормак артыкдыр. Сынамаган вә тәҗрибә кыйлмаган кешегә таянма, мең төрле түбәнчелекләр кыйлса да. Үзеңнән түбән дәрәҗәдәгеләргә мохтаҗ булудан бик саклан ки, моннан кыен эш юкдыр. Бурычтан бик саклан, әй угыл, кешегә бурычлы булдың, аңа кол булдың.

*Сиксән бишенче тәрбия.* Әй угыл, урланган нәрсәне алмактан бик саклана күр. Кирәк үзең урла, кирәк белә торып урлаган нәрсәне ал, икесе бәрабәрдер. Аңсыздан урланган нәрсә кулыңа керсә, үзеңдә калдырма, иясенә тапшыра күр.

*Сиксән алтынчы тәрбия.* Әмма, әй угыл, тышыннан дуслык күрсәтеп, эчендә дошманлык вә хөсед яшереп йөргән кешедән бик саклан. Бу заманның дусларына да ышанма. Берәү сине алдыңда мактаса, әлбәттә, белгел ки, һичшиксез, сине артыңда яманлый торгандыр. Тәҗрибә кыйлмый торып алданма.

*Сиксән җиденче тәрбия.* Әй угыл, яхшы сүз белән усалны юлга салырмын димә. Ахмак үз-үзенә кыйлган кадәр зарарны гакыллы адәм дошманына да кыйлмас. Әгәр, әй угыл, сине алдыңда мактасалар вә яхшылыгың өчен сиңа рәхмәт кыйлсалар: «Һай рәхмәт! мине мактыйсыз икән ләбаса», – димә, эчеңнән тын. Әгәр дусларым күп булсын дисәң, кеше эшенә катышма вә һичкемгә бәйләнмә – һәммә халык сиңа дус булыр.

*Сиксән сигезенче тәрбия.* Әй угыл, кулга керүе мөмкин булмаган нәрсәне өмет итмә. Гамәлең микъдарынча гына өмет ит. Мәсәлән, ун тиенлек гамәл кыйлып, ун сум өмет итәргә урын юк. Сынамаган вә тәҗрибә кыйлмаган эшеңә тотынма. Һаман үзеңнең белгән эшеңне эшлә.

*Сиксән тугызынчы тәрбия.* Әй угыл, кешенең күңеленә хилаф кылә торган сүзне телеңә китермә. Бер сүзне син пәйвайсыз әйтеп

җибәрерсең, ишеткән кешенең күңеле җәрәхәтләнә торган сүз булыр, күңеле рәнҗер. Кеше күңелен рәнҗетүдән бик саклан.

*Туксанынчы тәрбия.* Әй угыл, кешенең пәрдәсен ертма, ягъни халык алдында аның гаебен йөзенә әйтмә, халык алдында аны оялтма, бу бик яман холыкдыр. Кешенең гаебен вә килешмәгән эшен халык алдында әйтү – башына тукмак белән сукканнан да яманракдыр. Үзеңнең гаебеңне халык алдында үзеңә сөйләсәләр, яхшымы булыр?

*Туксан беренче тәрбия.* Үзеңнең кул астыңдагыларыңны һәркайчан разый кыйл: ягъни җәмәгатеңне вә хезмәтчеләреңне рәнҗетмә. Хезмәт хаклары булса, кулыңда асрама, хезмәт иткән өчен шунда ук акчасын бир, разый кыйл. Һәрбер күңелеңә килгән эшне эшләргә ашыкма, таки соңыннан үкенерлек булма, уйлап эш кыйл.

*Туксан икенче тәрбия.* Әй угыл, халык каршында гыйззәтем вә хөрмәтем артык булсын дисәң, ачык куллы вә икмәкле-тозлы, юмарт бул. Юмартлык белән дәүләт кимемәс, бәлки, дәүләтнең артуына сәбәпдер. Садака, хәер һичкайчан кешене бөлдермәс. Кешенең ярдәменә мохтаҗ булудан саклан. Әй угыл, кешенең миннәтен муеныңа йөкләмә, үзеңнең хәзинәңдә барына канәгать кыйл.

*Туксан өченче тәрбия.* Кешедән көтәргә нәрсә алып, бурычлы булма. Кешегә бурычлы булдың – аның колы булдың. Ахмак вә наданнар эшенә катышма, таки үзеңне хәкарәт вә тәхкыйрь кылмасыннар. Вә алар белән бәхәс кылышма, сүз көрәштермә, Локман хәким җавабын хәтереңдә тот.

*Туксан дүртенче тәрбия.* Әй угыл, ашаганда вә дәхи күп әдәпләр бардыр. Инсан булган адәмгә ул әдәпләрне ригаять кылмак ләземдер. Ашың хәлялдән булсын. Тәгам ашарга утырганда, кулыңны җу, вә дәхи тәгамнан бушагач, кулыңны җу, ашың

бәрәкәтле булыр. Әмма ашны бик кайнар ашама, кайнар ашта бәрәкәт кимдер. Хайван шикелле, ашаганда тәгамны иснәп карама. Кайнар булса, өреп ашама, өреп эчмә – болар әдәпсезлектән саналыр.

*Туксан бишенче тәрбия.* Аш алдыннан бисмиллаһ әйт, әй угыл, нигъмәтең хәлял булса. Әмма хәрам нигъмәткә бисмиллаһ әйтү нәһи эштер[134]... Әмма аш башлаганда бисмиллаһ әйтмәк җәһрән[135], ягъни тавыш белән әйтмәк тиеш, чөнки бергә ашагучыларга да тәнбия[136] булыр. Әмма ашап туйгач, әлхәмделиллаһ дип хәфиән[137] әйтергә кирәк, таки гайреләр туктамасын.

*Туксан алтынчы тәрбия.* Дәхи тәгамны, әй угыл, уң кулың белән аша, ләкин авызыңны тутырып капма. Вак-вак чәйнәп аша, ашың сеңешлерәк булсын. Дәстәрханга[138] ашны китергәч, дәррәү ашарга утыр, ашны көттермә. Дәхи ашап туйгач, дәстәрханнан ашны алмас борын торып китмә. Янә, күбрәк кеше килгән булып, бер генә кеше килмәгән булса, бер кеше өчен күп кешене көттермә.

*Туксан җиденче тәрбия.* Ашаган вакытта уңга-сулга карама, алдыңа гына карап утыр. Кешенең локмәсенә[139] вә кешенең кашыгына күз салма. Тәгамның уртасыннан алма, бәлки табакның үзеңә таба ягыннан вә читеннән алып аша. Вә алдыңа түкмичә вә тамызмыйча аша. Хосусән, мәҗлестә олуг адәмнәр булса, оят булыр. Эт ялаган шикелле, шапырдатып ашама. Дәхи дә тарелканың өстенә ятып ашама, мәҗлестә бу гаеп эштер.

*Туксан сигезенче тәрбия.* Әй угыл, мәҗлесендә олуглар булса, алардан элгәре ашка кул сузма, бу әдәпсезлек булыр. Дәхи гайреләр

[134] нәһи эш – тыелган эш
[135] җәһрән – кычкырып, тавыш белән
[136] тәнбия – искәртү
[137] хәфиән – яшерен, сиздермичә
[138] дәстәрхан – табын
[139] локмә – өлеш

ашап туйгач, кешедән калып ашап утырма. Күп ашамак мәзмүм эштер, хайван фигылеледер, күп ашаудан төрле авырулар пәйда буладыр. Аз ашамакта файда бардыр, җисмең сәламәт булыр, зиһенең саф булыр, хифызың[140] куәтле булыр.

*Туксан тугызынчы тәрбия.* Әй угыл, әгәр кунак чакырып зыяфәт кылсаң[141], кунагың аз булса, бергә утырып аша, әгәр кунакларың күп булса, үзең хезмәт ит. Әмма кунакларыңны ташлап китеп йөрмә. Дәхи гаҗиз итәрлек кадәр кунакларыңны кыстама. Ма хәзер[142] нигъмәтеңне кунакларың алдына ачык йөзең белән куй. Кунакларың барында җәмәгатеңә вә хезмәтчеләреңә ачуланма, орышма. Дәхи кунаклар белән мөгамәлә кыл, ят кеше кебек булып йөрмә.

*Йөзенче тәрбия.* Әй угыл, бинагяһ[143] кунаклар чакырып зыяфәт кылсаң, бер-беренә дошман кешеләрне бер мәҗлескә җыйма, бер табынга утыртма. Кунакларны танып, тиешле урыннарына утырт. Гыйлем әһелен бер җиргәрәк, вә гавам халкын янә үз алдына, вә байларны кәзалик һәр каюсын тиешле урыннарына утырт.

*Йөз икенче тәрбия.* Әй угыл, белмәгән вә тәҗрибә кылмаган кешеңнән саклан. Хосусән, әхлак бабында кеше белән кеше арасында аерма бик күптер. Изгелекнең кадерен белмәгәннәргә изгелек итмәгең әрәмдер. Чөнки күркәм холык ияләренә икрам[144] кылсаң вә изгелек кылсаң, алар сиңа кол булырлар. Вә әгәр изгелек кадерен белмәгәннәргә хөрмәт вә икрам кылсаң, тәмәрредләрен[145] арттырырлар вә шөкер итмәсләр. Андаен адәмгә изгелек итсәң:

[140] хифыз – хәтер
[141] зыяфәт кылу – кунак итү, сыйлау
[142] ма хәзер – нәрсә, ни бар
[143] бинагяһ – көтмәгәндә
[144] икрам – хөрмәт
[145] тәмәрред – үзсүзлелек, каршылык

«Бакчы, мин мондаен изгелеккә мөстәхикъ икәнмен ләбаса. Әле бу гына аз, аннан миңа фәлән кирәк иде, төгән кирәк иде», – дияр.

*Йөз өченче тәрбия.* Имде, әй угыл, кешесенә карап могашәрә вә мөгаләмә кылмак лязимдер. Һәркем янында ачык йөз белән йомшак сөйләш, яхшы кешеме, яманмы, мөселманмы яки гайре диндәме – һич тәфрикъ[146] кылма. Нитәкки, Аллаһе Тәгалә Муса галәйһессәламга әмер кылды: «Фиргавен белән йомшак сөйләш», – диде. Картларны хөрмәтләмәсәң, яшькә шәфкать кылмасаң, син өммәт түгел. Гарәпчә укый башлагач, бу сүзләрне хәдис китапларында күрерсең, әй угыл.

*Йөз дүртенче тәрбия.* Карендәшләрең белән, дусларың белән һәмишә йөреш, әмма ташлашып җибәрмә. Ягъни бик сирәк тә барма, таки сине онытмасыннар, көн саен да барма, таки синнән туймасыннар... Әй угыл, йөрешсәң, яхшы кешеләр белән йөреш, катышсаң, яхшы кешеләргә катыш.

*Йөз бишенче тәрбия.* Бер хәким үзенең углына әйтте: «Әй угыл, кемне теләсәң, аның белән мосахәбәт кыл, мөгамәлә кыл, йөреш, кунакка чакыр, үзең бар. Әмма биш төрле кемсәнә белән мосахәбәт кылма. Әүвәл ялганчы кеше белән мосахәбәт кылма, чөнки ялганчының сүзе су өстенә язган язу кебектер, сәбаты[147] юктыр, якынны ерак кылыр, еракны якын итәр. Дәхи ахмак вә надан белән мосахиб[148] булма, чөнки ахмак кеше сиңа файда иткән кебек күренсә дә, вакыйган, зарардыр. Вә дәхи тамгы[149] иясе белән мосахиб булма, чөнки тамгылы кеше мөттасил[150] синнән өмет итеп кенә торыр. Янә дәхи саран кеше белән юлдаш булма, чөнки саран

[146] тәфрикъ – аеру, бер-береннән аерым итү
[147] сәбат – ныклык, даимилек
[148] мосахиб – иптәш
[149] тамгы – комсыз, саран
[150] мөттасил – өзлексез, туктаусыз

кеше сиңа һичбер зарардан хали булмас. Әгәр дә аңар хаҗәтең төшсә, сине хур вә хәкарәт кылыр. Хосусән, сәфәрдә саран кеше белән юлдаш булма. Дәхи дә куркак вә җебегән кеше белән мосахиб булма, чөнки куркак кеше белән һич имин булмассың.

*Йөз алтынчы тәрбия.* Әй угыл, бер кавемне күрсәң, сәлам бир, ягъни бер җирдә күп кеше булса, яки күп кешегә очрасаң, аларга син сәлам бир. Чөнки бер кешенең күп кешегә сәлам бирмәге әүвәлидер, сәлам кайтармак, аларга фарыз эштер... Дәхи ат белән барган кеше җәяүлегә, җәяү барган кеше утырып торгучыга сәлам бирер. Әмма, әй угыл, сәлам бирсәң, ишеттереп бир, сәлам алсаң, ишеттереп ал. Ягъни сәламне ишеттереп бирмәсәң, гүяки син сәлам бирмәдең, әгәр ишеттереп алмасаң, кәзалик сәламне алмаган кебек буладыр.

*Йөз җиденче тәрбия.* Әмма балаларга сәлам бирү хосусында ихтиляф[151] бардыр. Ләкин балалар булса да, сәлам бирмәк артыктыр.

*Йөз сигезенче тәрбия.* ...Имде кием бабын да әйт дисәң, әй угыл, киемең бәһале булучылыкта вә арзан булучылыкта үзеңнең әмсалең вә мокариннарның[152] киеме кебек булсын, ягъни сиңа мәсәл кемсәнәләр ни бәһадә кием кияләр, син алар киеменнән бәһалерәк киемне кимә, чөнки ихтималдыр ки, аларда хөсед зоһур[153] итәр дә шикаятьтән хали булмаслар. Уртача кияргә кирәк, ифрат вә тәфрыйт[154] та ярамый...

*Йөз унберенче тәрбия.* Әй угыл, йорт салдырсаң, бик олуг итмә, бик биек итмә, үзең урнашып торырлык булса кифаядер[155]. Бик олуг йортның кобыхы[156] шулдыр ки: дөнья бер карарда

[151] ихтиляф – каршылык
[152] мокарин – якын
[153] зоһур – барлыкка килү
[154] тәфрыйт – чиктән тыш түбәнәйтү, киметү
[155] кифая – җитәрлек
[156] кобых – начарлык

тормыйдыр, ихтимал ки, эшең артка китсә, рәһен куярсың яки сатарсың, бәһа җиткереп алучы табылмас.

*Йөз уникенче тәрбия.* Әй угыл, өч нәрсә күңелне шатландырыр вә гакылны саф кылыр: гүзәл хатын, кифая кадәр ризык вә мунис[157] карендәш. Дәхи дүрт нәрсә бардыр ки, адәм аны ифрат вә хәддин тәҗавез күп кылса, һәлак буладыр. Әүвәл хатын белән күп маташса, адәм һәлак буладыр. Янә саед артыннан күп йөри торгач, адәм һәлак буладыр. Дәхи күп отыш уйнаса, адәмнең һәлакате андадыр. Дәхи дә күп хәмер эчсә, һәлак булмый калмыйдыр.

*Йөз унөченче тәрбия.* Әй угыл, берәү азгыннарга иярсә, ул кешенең дине бөтен булмас. Әгәр берәү бер фасикъны[158] мәдех кылса, халык арасында кыйммәте бетәдер.

[157] мунис – ияләшкән, өйрәнгән
[158] фасикъ – әхлагы бозык кеше

*Каюм Насыйри*

# *Әхлак рисаләсе*

# Әхлак рисаләсе[159]

Бисмилләһи-рахмани-рахим...

Ошбу «Әхлак рисаләсе», балаларга явыз холыктан сакланып, изге холык илә холыкланмак өчен, ата-ана нәсихәте мәнзилендә нәсихәттер. Мәгълүм ула ки, адәмне башка хайваннан аера торган сыйфат нотыктыр, ягъни сүз сөйләшүдер. Аның өчен, камил адәм булмак өчен, гыйлем эстәмәк вә белмәгәнне өйрәнмәк, изге холык илә явыз холыкны белмәк, вә изге холык илә холыкланып, явыз холыктан сакланмак ляземдер.

Адәм ашар, эчәр, йоклар... Башка хайваннар адәм кебек ашар, эчәр, йоклар... Моның кебек сыйфатларда адәм илә хайван икесе дә бердер. Имде адәмнең башка хайваннардан аермасы шулдыр ки: адәмнең гакылы бар, фикерли белә, теле бар, сөйләшә белә. Ошбу тел вә сөйләшә дигәнебез дәхи гыйлем илә вә белмәгән нәрсәләрне белгән кешеләрдән өйрәнеп белмәк илә, вә китаптан укып фәһемләмәк илә булыр. Әмма адәм бу мәзкүр сыйфат илә башка хайваннардан аерылгач та, һәнүз камил адәм булмыйдыр. Камил адәмилек дәхи изге холыклы булмак вә явыз холыктан сакланмак илә хасыйл булыр. Ошбу җәһәттән балалар акны-караны аерып белә башлаган вакытларында, яхшы вә яман нәрсәләрне дәхи аңлатмага иҗтиһад вә гайрәт итмәк бик лязем нәрсәдер. Чөнки балалар яшь агач кебектер: яшь агач һәр никадәр кәкре булса да, төзәтмәк асаттыр. Шуның кебек адәм дәхи кечкенә вә яшь вакытта тәрбияне кабул итмәге җиңел булыр. Ләкин үсеп җиткәч, хосусан хәрам вә мәкер нәрсәләрдән ләззәт алып, явыз вә

[159] Тәрҗемә 1911 елгы басма нигезендә башкарылды:
Насыйри Каюм. Әхлак рисаләсе. Казан: Өмет, 1911. – 24 б.

яман холыкларга гадәтләнгәннән соң, аны шундый яман холыклардан аерып изге юлга күндермәк гаять мөшкел эштер.

Әй газиз бала! Агяһ бул: сиңа бераз нәсихәтем бар. Әүвәл сиңа белмәк лязем ки, бу дөньяны юктан бар иткүче вә безләргә ризык биргүче ул Аллаһы Тәгалә булган өчен, кичә-көндез аның пакь затына гыйбадәт итмәк вә нигъмәтләренә шөкер итмәк, вә аннан куркып явыз холыклардан вә яман фигыльләрдән тыелмак, вә даимән изгелек кылмак динебезгә вә гакылыбызга бинаән өстебезгә фарыздыр.

## *Галимлек вә наданлык*

Әй газиз бала! Агяһ бул: адәмгә иң әүвәл бигрәк кирәк вә бигрәк лязем нәрсә – гыйлемдер. Вә гыйлем дигәнебез белмәгән нәрсәне өйрәнеп вә сорашып белмәктер. Вә наданлык дигәнебез белмәклеге лязем булган нәрсәне белмәссезлектер. Бу наданлык кешене игътибардан чыгара торган нәрсәдер, вә хайван дәрәҗәсенә кертә торган сыйфаттыр. Кайда барса да, надан кешенең кадере юктыр. Имде гыйлем өйрәнүгә ниятеңне яхшы дөресләп, укырга-язарга вә һөнәр вә мәгърифәт хасыйл итәргә иҗтиһад кыл. Чөнки гыйлем вә мәгърифәт иясе һәр җирдә хөрмәтле булып, халык арасында кадере зур булыр, наданлык һәркайчан сине үкендерер. «Һай, гомерем үтте, сабак укымадым, надан калдым» диярсең, хәтта тикшереп сорашып карасаң, шулай дип үкенүчеләр бик күптер. Үкенсәләр дә, ни файда! Наданлык шундый бер сыйфаттыр.

Әмма наданлык сыйфаты бик начар сыйфаттыр. Надан кала күрмә, сабак укыганда белмәгән вә аңламаган сүзеңне хәлфәңнән сора, кеше укып кына белми, сорашып күбрәк гыйлем хасыйл була. Ни укысаң да, сабак алган вакытта белми китәргә бер дә ярамас,

белмәгән сүзеңне хәлфәңнән, я башка кешедән сорарга да оялма... Хәлфәңне борчып бетер, вә бу тугрыда хәлфә сиңа бер дә рәнҗемәс. Имде һәркайчан мәсьәлә сорасаң, ашыгып сорама, үзгә гыйбадәткә вә мөгамәләгә тиешле мәсьәләне сора, урынсыз ашыгып сорасаң вә тиешсез мәсьәләне сорасаң, оятка калырсың, наданлыгың беленер...

## *Ригаять вә ата-ана хакы*

Кеше атасына, анасына вә остазына хөрмәт итмәк вә гыйzzәтләмәк[160], вә аларны олугламак, вә һәр урында ригаять[161] итмәк бик лязем эштер. Вә аларны хәкарәт кылмак[162] вә хурламак гөнаһ эштер. Ата-анаңа хөрмәт итмәсәң вә хәлфәләреңне ригая кылмасаң, гомердә изгелек күрмәссең. Ата-анаңа каршылык итмә, телең вә фигылең илә аларны рәнҗетмә, һәр тугрыда аларга мотыйг[163] бул. Сүзләрен тыңла, вә аларга акаеп карама, кычкырып әйтмә. Ата-анаңа хитаб кылсаң[164], «әти, сез», «әни, сез» диген, «әти, син», «әни, син» дип әйтмә, бу әдәпсезлек булыр. Атаң-анаң каршында вә хәлфәң янында әдәп илә генә торырга тиеш, вә һәр хосуста аларга ригая кылмак кирәк. Ата-анаң вә остазларың хакы бик зурдыр, ата-ананы рәнҗеткән кеше оҗмахка кермәс. Һәр заман яман холыклардан вә явыз фигыльләрдән бик саклан. Әгәр хидмәт[165] бирсәләр, «ләббәйкә»[166] дип, җан вә күңелеңнән разый булып, хидмәт ит, ниттәки борынгылар әйткәннәр:

[160] гыйzzәтләмәк – кадерләү
[161] ригаять – хөрмәтләү, олылау
[162] хәкарәт кылу – хурлау, кимсетү
[163] мотыйг – буйсынучы, баш июче
[164] хитаб кылу – эндәшү, мөрәҗәгать итү
[165] хидмәт – йомыш, эш, хезмәт
[166] ләббәйкә – боерыгыз, йомышыгызга хәзермен, баш өсте

*Ата берлән анаңа хидмәт иткел күп-күп,*
*Иртә торып һәр көндә аякларын үп-үп,*
*Һәр ни әйтсә, аларның сүзен күргел җөп-җөп,*
*Сабыр кылгыл аларга, кыйнасалар дөп-дөп.*

## ***Кязиб***[167]

Ягъни ялган сөйләшмәк вә алдамак бу дәхи бик яман холыктыр вә хәрам эштер. Ялганчы Аллаһы Тәгаләнең дошманыдыр, моннан бик сакланмак тиештер. Башың китсә дә, ялган сөйләшмә. Тугрылык аркасында баш китә торган эшләрдән котылырсың, ялганчылык сыйфаты олуглар каршында вә изгеләр янында зур гаеп эштер. Ялган сөйләшергә гадәтләнгән кеше, күп вакытта ялганчылыгы заһыр булып, оятка каладыр, вә изге адәмнәр каршында әсла кадере булмыйдыр, аның чын сүзенә дә ышанмыйлар. Ялган сөйләшмәгә вә кешене алдамага телеңне өйрәтмә, тугры сүзле бул. Бер мәртәбә ялганчылык илә атың чыкса, мең мәртәбә дөрес сүз әйтсәң дә, ышанмаслар.

## ***Нәмимә вә нәммамчылык***[168]

Ягъни сүз йөртмәк дигән нәрсәдер. Бу һәм ялганчылык шикелле, бәлки зиядә кабахәт сыйфаттыр, вә шәригатебездә гаять мәзмүм вә гөнаһ эштер. Сүз йөртү дигәнебез, мәслә, бер кеше икенче бер кеше хакында яман сүз сөйләсә, яки яман эш кылса, тиз үк аны ул кешегә барып сүз илә, яки хат илә ирештереп, фәлән кеше синең хакында шулай әйтте, болай әйтте, яки шулай кылды, болай кылды

[167] кязиб – ялган
[168] нәммамчылык – әләк, яла, сүз йөртүчелек

дип сөйләмәктер. Кирәк ни җәһәттән булсын, ягъни ул кешедән бер файда өмед итеп, яки ул кешегә якынлыкны арада кылып сөйләсен, моны нәммамчылык диерләр, бик явыз холыктыр. Мондый эштән тәнең, җаның илә саклан. Бу сыйфатларга алыша күрмә, бу сыйфат илә исмең чыкмасын.

## *Нифак[169] вә монафикълык*

Ягъни икейөзлелек диерләр, бу һәм явыз холыкларның берседер. Монафикълык[170] диерләр, ике дус кеше арасына кереп, яки ике дошман кеше арасына кереп, һәрберсенә бер төрле сүз сөйләп, дуслыкларын китәргече яки дошманлыкларын арттыргучы бер сыйфаттыр. Үзең мондый холык илә холыклану түгел, хәтта мондый холыклы адәмнәр янына да барма, аларның кәсафәте[171] сиңа да тияр. Шәригатебездә бу бик кабахәт сыйфаттыр. Аллаһы Тәгалә сөймәгән эштер. Бу сыйфатларга вә мондый хәрам эшләргә гадәтләнмә. Монафикъ дип исмең чыкса, бер мәҗлестә дә кабул итмәсләр.

## *Хәсәд вә көнчелек*

Хәсәд, ягъни көнчелек диерләр, берәүдә булган мәртәбә вә дәрәҗәне күреп, яки яхшы нәфис кием, яки ат, яки йорт, яки боларга охшашлы башка бер, үзенең нәфесенә муафикъ яхшы нәрсәләрне күреп көнләшмәк, вә ул кешедән бу нигъмәтләр китсә иде дип теләмәктер. Бу дәхи әхлак зәмимәнең, ягъни явыз холыкларның олугыдыр вә мәзмүм сыйфаттыр. Вә көнче кешенең үзенә бик

169 нифак – икейөзлелек
170 монафикъ – ике йөзле, эчкерле
171 кәсафәт – начарлык, зыян

зарарлы булган бер авырудыр. Мондый көнчелек сырхавы берәүнең башына керсә, теге кеше үлми торып, яки ул нигъмәтләр аннан китми торып, көнчелек авыруыннан айнымас. Бу холыктан бик саклан, һичкемгә, һичнәрсә хакында көнчелек кылма. Чөнки син аның нәрсәсенә көнчелек кылсаң да, ул нәрсә сиңа килмидер. Болай көнчелек итүнең бер файдасы юктыр. Мәгәр кешедә андаен яхшы нәрсәләр күреп, көнчелек кылмыйча, һәр кеше шундый нәрсәне Аллаһы Тәгалә миңа да бирсә иде дип, сәбәбенә керешмәк кирәк. Кибетче булсын яки һөнәрче булсын, күршең яхшы сату иткәнен күреп яки һөнәр кылганын күреп, ул файда итә, мин файда итә алмыйм дип көнчелекне күңелеңә китермә. Ул миннән артык файда итмәсен дип аның зарарына касд[172] кылма. Көнче булсаң, булмасаң, Аллаһы Тәгалә үлчәп биргәннән артыкны ала алмассың.

## *Ялкаулык*

Бу ялкаулык һәм балалар хакында һөнәрсез вә надан калмагына сәбәп була торган бер сыйфаттыр. Мәсәлән, балалар хакында мондый сыйфат: мәктәпкә бармаска вә укымаска, вә язмаска бер хәйлә табып, сабак вакытында буш калмактыр, вә файдасыз нәрсәләр илә шөгыльләнеп, вакытны буш уздырмактыр. Бәгъзе вакытта сабак укый торган баланың ялкау булмагына атасы-анасы да сәбәпче буладыр. Я «бүген мәктәпкә бармасаң да ярар, кунак бар», я «бүген бармасаң да ярар, фәлән җиргә барасы бар, фәлән эш бар», я «бүген бармасаң да ярар, бүген Ташъаякка барасы бар» дигән шикелле бәһанәләр[173] хосусан ялкау балаларны сабак укудан буш калдыра торган сәбәплләрдер. Ялкау бала моның кебек сәбәпләрне

[172] касд – явыз ният
[173] бәһанә – сылтау, ялган сәбәп

көтеп кенә торса кирәк, сабак баласын тиешсез урында иркәләмәк һәм ялкау булмагына сәбәптер.

Имде, әй газизем, мөбарәк бала! Сабак укыган вакытыңда юк-бар эшләр илә шөгыльләнеп, кыйммәтле вакытыңны бушка уздырсаң, бервакытны «һай, укыр вакытымда буш уздырдым, бер һөнәр өйрәнмәдем, бер нәрсә дә белми калдым» дип бик үкенерсең. Син, гакыллы бала, аны белерлегең бар. Гыйлем вә һөнәр өйрән, сабак укы, язу яз, гомереңне буш уздырма. Бәет булсын, җыр булсын, хикәят булсын, укы. Укырга теләк күнсен, һәр ни булса, укы. Гакылың тулып җиткәч, үзең кирәкле гыйбадәтеңә вә мөгамәләгә тия торган китапларны укымага асат булыр.

## *Хәйләкәрлек*

Бу сыйфат һәм балалар хакында ялкаулык маддәсеннәндер. Ягъни ата-анасын вә хәлфәсен, вә башка адәмнәрне төрле ялган сүзләр илә алдап, сабак укудан, язу язудан котылып, үзенең күңеленә килгәнен эшләмәк өчен бер хәйлә эзләмәктер. Мәсәлән, ата-анасына кайтып, хәлфә өйдә юк яки ашка китте, яки хәлфәнең кунагы бар, яки кәгазем юк, карам юк, яки мәдрәсә малайлары миннән көләләр, мыскыл итәләр дип егълап, сабак укудан котылмак өчен, ялкаулыктан бер кыйсемдер[174]. Ата-анасы вә хәлфәсе мондый эшләрне тикшермәк кирәк. Балалар хакында бу мәзмүм сыйфаттыр. Мондый балаларның дистәсе бер тиендер, ягъни асла кадере юктыр. Имде, әй газизем, бу сүзләрне ишеттең, гакылың булса, аңларсың, алай хәйләкәр булма.

[174] кыйсем – өлеш, бүлек, бүлем

## *Шаянлык*

Бу һәм балалар хакында гаять әшәке эштер вә ярамас сыйфаттыр. Үзеңә генә түгел, моның башка сабак балаларына да зарары бардыр. Мәсәлән, малайларны көлдерәм дип, төрле-төрле кыяфәтләргә кермәк, төрле нәрсәләр кылмак, вә теленә килгән юк сүзләрне сөйләп, балаларны көлдермәк кебек сыйфатлардыр.

Имде, әй газиз бала, мондый фигыльләр илә шаян малай дип исемең чыкса, берәү янында да кадерең булмас. Башка сабак балалары да, уйнап-көлдереп, безнең сабагыбызны укытмый дип, атаңа-анаңа шикаять кылсалар, хәлфәңә әйтсәләр, атаң-анаң кыйнар, хәлфәң кыйнар, ничек чыдарсың! Мәктәпкә баргач, үзеңне сабак балалары да яратмас, урамда очрасалар да, әнә әлеге шаян малай дип, үзеңә төртеп күрсәтерләр, оятлы булырсың. Мондый эшләр сабак баласына килешмәс, бик саклана күр.

## *Бәдзәбанлык*

Ягъни әшәке вә кабахәт сүзләрне сөйләүчелек. Балалар хакында бу һәм гаять сакланачак сыйфаттыр. Үзенең иптәшләре булгучы сабак балаларына вә гайре адәмнәргә кабахәт сүз әйтмәк, сүкмәк, син-каф хәрефләрен телдә күп йөретмәк гаять гөнаһ эш булмак җәһәтеннән, берәүгә дә кабахәт сүз әйтүчән булма. Мондый кабахәт фигыльләр илә иптәшләреңне рәнҗетмә, дәхи мәктәпкә барганда-кайтканда, китап Коръәнеңне куеп, башка балалар илә сүгелешеп, тәүбәләшеп уйнап йөрмә. Хосусән мәктәптә сабак укыган вакытта мондый нәрсәләр бик гаеп эштер.

## *Угрылык*

Бу дәхи динебездә вә шәригатебездә иң олуг явыз холыклардандыр вә һәм угрылык бик олуг гөнаһ вә хәрам эштер. Бу угрылыкка салынган кеше, вә угырлап тотып, угрылыгы заһыр булган кеше шәригатьтә дә олуг җәзага мөстәхикъ буладыр. Төрмәгә ябалар, Себер җибәрәләр, мондый фигыльләргә күңеленне салма. Мәктәптә укыганда да кемнең каләмен, кемнең кәгазен сорамыйча алма. Һәм кешенең нәрсәсен уйнап кына да алма, вә уйнап яшереп тә куйма. Үзеңнән һәмма сабак балалары бизәр, берсе дә дус күрмәсләр. Бу малай угры дип карак исемең чыкса, халык арасында хур булырсың. Әгәр бу сыйфатка өйрәнсәң, әүвәл каләм угырларсың, аннан соң кешенең яулыгын угырларсың, бара торгач ат угырларсың. Ахырында тотылып, Себер китәрсең. Бу бик яман эштер, саклана күр, кешенең тузан кадәр нәрсәсенә хыянәт кылма.

## *Ифшаэ сер*

Ягъни авызда сүз тормаганлык, бер яшерен нәрсәне күргән вакыт вә яшерен эшне ишеткән вакыт аны сакламыйча, һәр кешегә сөйләп йөрмәк, белдермәк, яман вә ярамас сыйфаттыр. Хосусән бу нәрсәне яки бу сүзне кешегә әйтмә, вә сөйләмә дисәләр, аны яшермичә сөйләп йөрмәк гаять яман эш булганга күрә, моннан бик сакланмак кирәк. Әгәр дә мондый фигыльнең барын белсәләр, янында берәү дә сер сүзне сөйләшмәс булыр. Сөйләшеп торган вакытларында барсаң, фәлән килде дип сүзләрен туктатырлар, һичкем каршында игътибарың вә кадереӊ калмас, аның авызында сүз тормый дип, бер мәҗлескә дә кертмәсләр.

## *Хәкарәт вә хурлау*

Бу дәхи һәркем хакында яман вә ярамас фигыльдер. Олуг вә кечкенә булуына карамыйча, кешене хәкарәт кылмак вә хурламак адәмилек җәһәтеннән вә әдәп мөрәүвәт[175] җәһәтеннән һичбер вакытта бер кеше хакында лаек түгелдер. Үзеңнән кечкенә булса да, фәкыйрь булса да, вә теләнче булса да, һичкемне хәкарәт кылма вә һичкемнән мәсхәрә кылма, вә мыскыл сүзләр сөйләшмә, вә хәкарәтне белдерә торган ляфызлар илә вә кабахәт сүзләр илә берәүгә дә хитаб кылма. Вә әгъзасында гаебе булган адәмнәргә таз, аксак, чулак дигән кебек сүзләрне әйтеп кычкырма. Бу бик яман фигыльдер. Болай булсаң, үзеңне һичкем яратмас. Һәркемгә – байга, фәкыйрьгә, олугка, кечкенәгә – тәвазыйглыклы[176] вә түбәнчелекле бул, тәмле-татлы сүзле бул, әдәпле бул.

## *Интикам*

Ягъни үч алмак вә нәфесәнияткә булышмак. Бу сыйфат дәхи һәркем хакында явыз холыклар җөмләсеннәндер. Ягъни бер кеше синең хакында җаныңга тиярлек бер сүз әйтсә яки бер-бер эш кылса, аны онытмыйча, күңелеңдә саклап, уңае килгәндә аннан үч алмак, яки бу хосуста аның бер дә гөнаһысы булмаса да, үч итеп аның хакында бер яман эш кылмак адәмилеккә асла ярый торган эш түгелдер. Явызлык иткәнгә мөмкин кадәр изгелек итәргә тырыш. Кешегә үч итмәк вә кешедән үч алмак ирлек вә мөселманлык эше түгелдер. Явыз холыклардан бик саклан. Яман кеше дип исемең чыкмасың.

[175] мөрәүвәт – кешелек, галиҗәнаплык

[176] тәвазыйглык – түбәнчелек, түбән дәрәҗәле итеп күрсәтү

# *Сәдакать*[177]

Ягъни тугрылык чын мөселманлык галәмәтедер, фигылендә вә сүзендә тугры булмак гаять күркәм вә изге холыктыр. Кешенең затында, сүзендә вә фигылендә тугрылык булса, ул кеше һәртөрле халык каршында кадерле буладыр. Мондый кешенең бәһасе юк. Әгәр мыскаллап сатсалар, мыскалына бер алтын тәңкә бирерләр. Имде, әй газизем, бу мәдех сыйфатны ишеттең, мондый сыйфат үзеңә хасыйл итә күр. Тугрылык дигән сүзнең ляфызында гына да нинди хасыять[178] бар! Ике мокабил[179] сыйфатка каршы торадыр. Ялганчы түгел, кешене дә тугры диерләр, угры түгел, кешене дә тугры диерләр.

# *Вафадарлык*

Ягъни кылган вәгъдәңгә вафа кылмак, вәгъдәдә тормак сыйфаты. Бу дәхи кешедә камил адәмилек вә мөселманлык галәмәтедер. Вә гаять изге сыйфаттыр. Вәгъдәсендә тормаган вафасыз кешене һичкем дус тотмас. Шуның өчен:

*Әгәр ирмен дигәннең вәгъдәсе төз,*

*Әгәр төз булмаса, андыйдан өмед өз,* –

дигәннәр. Вафалы вә мөрәүвәтле булырга кара. Һәркем каршында дус күренерсең. Кулыңнан килгән кадәр дусларыңа вә карендәшләреңә изгелек кыл. Вафа вә мөрәүвәт иясе булган кеше һәртөрле халык каршында мәкъбүл вә мөгтәбәр кешедер, вә һәр каюсы мактаулы буладыр. Мондый мактаулы сыйфатлар илә

[177] сәдакать – тугрылык, дуслык, туры сүзлелек
[178] хасыять – үзлек, үзенчәлек
[179] мокабил – кара-каршы

сыйфатланмасаң, син адәм дә түгел, әгәр адәм булсаң, кара илә акны, яхшы-яманны аерып белергә тиеш. Шуларны аерырлык кадәр генә синдә гакыл бар. Үскән саен бишеккә кермәссең.

## *Канәгать*

Канәгать дигән нәрсә дәхи кешегә рәхәт вә игътибар китерә торган бер изге сыйфаттыр. Ягъни ашамак, эчмәк, кимәк, салмакта вә дәхи моңа охшашлы нәрсәләрдә Аллаһы Тәгаләнең биргәне кадәресенә разый булып шөкер итмәктер. Канәгать иясе булган адәм, дөньяда күп зәхмәт чикмичә вә мал күбәйтмәк дәрдenә[180] төшмичә, газиз гомерен рәхәтлек илә тынычлык илә кичерер. Канәгатьсез булган кешене ач күзле диерләр, ач күзле булмак һәм мөселманлыкка лаек эш түгелдер. Азга канәгать кыл, канәгатьсез булып Аллаһы Тәгалә үлчәп биргәннән артыкны ала алмассың. Канәгать олуг байлыктыр. Әмма һиммәт[181] вә мөрәүвәт иясе булып, изге эшләрдә вә изге ният илә үзең өчен вә һәм якыннарыңа вә башка адәмләргә файдасы гам[182] булсын өчен гыйлемлек эстәп, һөнәр вә сәнәгать өйрәнеп, вә сату-алу кылып, хәлял мал кәсеп итмәк яхшы эштер. Фәкать хирыслык вә саранлык илә мал арттырмак ниятендә булмак яман сыйфаттыр. Хирыс кешене дөнья малы да туйдырмас.

[180] дәрд – теләк, омтылыш, кызыгу
[181] һиммәт – теләккә омтылу, тырышлык
[182] гам – гомуми, һәркемгә караган, күмәк

## *Изгеләргә якынлык*

Ягъни һәрдаим изге адәмнәр илә катнашып, яман вә явыз адәмнәрдән ерак булмак вә явыз холыклардан сакланмак, яхшы вә изге сыйфаттыр. Чөнки кеше һәрзаман яхшы кешеләр илә, изге вә галим адәмнәр илә катнашып, кичә-көндез аларның мәҗлесендә булса, аларның фигыле вә холкы илә холыклана вә аларның табигатен отып аладыр. Ягъни берәүнең мәҗлесенең берәүгә әсәре бар, вә берәүнең табигатен икенче берәү отып аладыр. Моннан лязем булып килде ки, яманнар вә явызлар мәҗлесендә булсаң, алар шикелле булмый хәлең юк. Яманнарга катнашудан вә яманнар мәҗлесендә булудан бик саклан. Бара-бара аларның мәҗлесе әсәр итеп, үзең дә яманга үрелеп китәрсең, вә яман юлга кереп китеп, азгыннар җөмләсеннән булырсың.

## *Гаҗәлә вә ашыгу*

Ягъни ашыкмак вә эшнең ахырын тикшермичә эш кылмак дәхи мөселманлыкка килешми торган сыйфаттыр. Ашыкмак шәйтан фигыледер, һәрбер囲 эштә тәэнни[183] вә вәкар кирәк, ягъни акрынлык вә ашыкмаслык кирәк. Сүз сөйләсәң, ашыгып сөйләмә, эш кылсаң, ашыгып кылма. Кешедән бер нәрсә сорасаң яки бер мәсьәлә сорасаң, ашыкма. Әүвәл сорыйсы нәрсәңне вә сорыйсы сүзеңне күңелеңә беркет. Килешерме, килешмәсме дип уйла. Вә мәсьәлә сораганда да үзеңә кирәклерәк мәсьәләне сора. Бер галим күргәч тә «тукта, бер мәсьәлә сорыйм» дип ашыгып сорама. Сүзне әйткәч, кире кайтарып алып булмыйдыр. Урынсыз сорауның мәгънәсе юк, соңыннан оятка калырсың. Укып кына кеше галим булмый, мәҗлес күрә-күрә,

[183] тәэнни – ашыкмау, уйлап эш итү

гыйбрәтләр ишетә-ишетә галим буладыр. Бер мәсьәлә ишетеп аңламый калсаң, кайтарып сорамак гаеп эш түгелдер. Кешенең сүзен вә сөален ишетер-ишетмәс, аңлар-аңламас, ашыгып җавап бирмә.

## *Гыйнад вә каршылык*

Ягъни атаң-анаңның нәсихәтен вә сүзләрен вә хәлфәләреңнең нәсихәтен тыңламыйча, вә изге адәмнәрнең нәсихәтен кабул итмичә, карышып тормак вә аларга каршы сүз кайтармак иң яман холыктыр. Һаман үзең теләгәнне генә кылмак адәмлек сыйфатыннан тыштыр. Атаң-анаң изге булса, алар угыл дисә, ул изге ата-ана яманлыкка боермас, нинди явыз ата-ана да угырла, зина кыл димәс. Әгәр ата-анаң бу сыйфатта булса, хәлфәнең нәсихәтен тот, һичкайчан хәлфә яманлыкка боермас. Шуның өчен хәлфә хәтта ата-ана хакыннан олуграк димешләр.

## *Нәзафәт вә пакьлек*

Ягъни пакьлек динебездә вә шәригатебездә вә гакылыбыз каршында игътибар кылмага лязем булган бер сыйфаттыр. Һәртөрле нәҗасәттән[184] пакь булмак бик лязем нәрсәдер. Пакьлек мәмдух нәрсәдер вә табигатьнең хушлыгына сәбәптер. Моның зыяды шакшылыктыр, ягъни тәнеңне вә киемеңне кабахәт вә шакшы йөртмәктер. Кешенең киеме иске булмак гаеп түгел, әмма шакшы вә пычрак булмак олуглар каршында бик гаептер. Өсте-башы, авызы-борыны вә куллары пакь булган балаларны һәркем күрсә, аннан хушланыр вә аның табигатенә мөлаем тоелыр. Әгәр өсте-башы,

[184] нәҗасәт – пычраклык

тирә-ягы шакшы вә нәҗес булса, вә табигатькә мәкруһ[185] яман исләр булса, андый балалардан яхшы кешеләр җирәнәдер, яннарына якын да китермәсләр. Бер баланың чәче җиту булса, тырнагы җиту булса, борыныннан маңкасы чыгып торса, киеме шакшы булса, үзең дә яратмассың. Кешедә бер ярамаган яман сыйфатны күрсәң, аннан гыйбрәтләнеп үзең дә саклан. Синнән дә шулай көлерләр, өстеңне-башыңны пакь итмәк лязем булган шикелле, югарыда мәзкүр явыз холыклардан күңелеңне һәм пакьләмәк бик лязем эштер. Аллаһы Тәгалә синең күңелеңә карый, өстеңә-башыңа карамый. Аллаһы Тәгалә карый торган җирне бигрәк пакьләмәк тиеш. Аллаһы Тәгаләгә мәһабәтле күренер өчен эчеңне пакьлә. Дөнья әһеленә мәһабәтле күренер өчен тышыңны пакьлә. Кече яшьтән үк даим таһарәт илә йөрергә гадәтлән. Даим таһарәт илә йөргән кешенең ризыгы киң булыр дигән китапта.

## *Сәхавәт вә юмартлык*

Юмартлык изге холыкларның иң яхшысыдыр, ягъни үзеңдә вә мөлкеңдә булган нәрсәләрдән тиешле вә шәригать кушкан вәҗһе үзрә миннәт кылмыйча, күңелең хушлыгы илә вә көчләнмичә, камил ихтыярың илә гайрегә бирмәкне юмартлык диерләр. Берәүгә хәрам исерткеч эчәргә акча бирсәң, бу шәригать кушкан вәҗһе үзрә булмады, әлбәттә, юмартлык димәсләр, явызлыкка ярдәм биргән өчен үзең гөнаһлы булырсың. Берәүгә гөнаһ кылырга сәбәпче булган кеше дәхи гөнаһлыдыр. Аллаһы Тәгалә биргән һәртөрле нигъмәтләрдән мөрәүвәтең кадере башка карендәшләреңә, дус-ишләреңә, исраф кылмыйча, биреп, ингам вә икрам итмәк мөселманлык шартларыннандыр. Мәсәлән, бари акча вә бүләк

[185] мәкруһ – начар күрелгән, ямьсез

бирмәк вә якын дусларыңны мәхәббәт йөзеннән зыяфәт итмәк вә һәркемне дәрәҗәсенә күрә хөрмәт итмәк дуслык вә мөселманлык шартларыннан. Һәр адәм каршында мәкъбүл вә мәмдүх эштер вә изге догага сәбәп булгучыдыр.

## *Саранлык*

Саранлык диерләр кулыңда вә мөлкеңдә булган ма хазәрә нәрсәдән берәү сораганда үзеңнең мөрәүвәтеңә карап вә аның зарурәтенә карап бирмәссезлек сыйфатыдыр. Вә бу саранлык әхлак зәмимәдәндер. Вә мөселманлыкта ярамый торган сыйфаттыр. Әгәр каты вә хәсис[186], вә саран булсаң, һичбер дустың да булмас, догачың да булмас. Юмартлык малны киметмәс, саранлык ризыкны арттырмас.

## *Ярдәм вә шәфкать*

Дәхи изге холыклардандыр, ягъни башкаларга ярдәм вә шәфкать итмәк вә кызганып мәрхәмәт итмәк мөселманлыкның олуг шартларыннандыр, вә мәдех сыйфаттыр. Берәүнең бер көче җитми торган вә үзенең кулыннан килми торган бер мәслихәте булса, вә синнән ярдәм эстәсә, урынына күрә, кодрәтеңнән килгән кадәр аның диненә карамаска кирәк. Мөселман булсын, кирәк кайсы халыктан булсын, ярдәм вә шәфкать ит. Кирәк кул илә вә көч илә, кирәк акча илә, вә кирәк телең илә булсын, ярдәм вә шәфкать итмәк динебездә вә шәригатебездә гаять изге эштер. Бу рәвешчә берәүгә ярдәм итсәң, бер көн синең дәхи хаҗәтең төшкән вакыт сиңа да ярдәм итүчеләр булыр. Саранлык кылып, мондый хосуста мөрәүвәт кылып, ярдәм

[186] хәсис – әшәке, түбән, саран кеше

итмәсәң, бер тарлык көнеңдә сиңа да ярдәм вә иганәт итүче табылмас. Мәктәп балаларыннан берәү бер ярдәм эстәсә, кулыңнан килгән кадәр ярдәм ит. Бу фәкыйрь, мин бай баласы димә, замана хәле бик тиз үзгәрүчәндер. Дүрт-биш ел эчендә байлар фәкыйрь була, фәкыйрьләр баеп китәдер. Хәзердә ярдәмнәре тимәсә дә, бәлки ахыр көнеңдә шул балаларга ихтыяҗың төшәр. Берәүнең бер яхшылыгы тисә, үлгәнче аны онытырга кирәкмәс. Чын мөселманлык эше шулдыр. Олуг димә, кече димә һәркемгә хидмәтчән бул, берсе дә кулыңа ябышып калмас. Рәхмәт, кулың-аягың сызлаусыз булсын дисәләр дә, кабул булса, шул сиңа җитәр.

## *Өлфәт вә хәсән мәгәшарә*

Ягъни кеше бер-бере илә күрешеп мосахәбәт кылышканда вә мөгамәлә кылышканда көләч йөзле вә татлы сүзле булып утырышмак изге холыкларның берседер. Күңел рәнҗетә торган сүзләрне вә адәмнең җанына тиярлек сүзләрне әйтүдән бик саклан. Һичвакытта кешенең хәтерен калдырма, телең илә вә фигылең илә, ягъни тиешсез сүз әйтеп вә тиешсез эш кылып, берәүнең дә хәтерен калдырма. Берәү шулай үз хәтереңне калдырса, гомердә онытмассың. Кеше янында ачуланып торган шикелле тормак, вә сүз сөйләшкәндә кешенең башына суккан шикелле каты-каты сөйләшмәк, мөселманлыкка хилафтыр. Мондый эшләр үзен кешедән әгъла[187] тотудан вә тәкәбберлектән киләдер.

[187] әгъла – югары

## Әдәп мәгашарәт

Әмма өлфәтнең вә дус-иш илә мәҗлестәш булып сөйләшеп утырмакның әдәбе ошбудыр ки: кеше сөйләшкән вакытта тыңлап торып, сиңа бер-бер сүз әйтергә нәүбәт итсә, ашыкмыйча җавап бир, сүзеңне һәркем аңларлык итеп аерып-аерып әйт, сүзеңне бере артыннан берсен ашыгып-ашыгып әйтмә. Сүзеңне тыңлап торган адәмнәргә авыр килерлек озын-озын гыйбарә илә сөйләмә, әйтәсе сүзеңне әүвәл башында тәртип кылып, кыскалык илә морадыңны аңлатырга тырыш. Мөнәсәбәтсез вә кешене көлдерә торган сүзләр сөйләмәк әдәпсезлектәндер. Сүзеңне ишеткән адәм бу ахмак бала икән димәсен, вә дәхи мәҗлестә кеше сөйләшкәндә тыңлап тор, алар сүз әйтеп бетермәс борын сүз башлама, болай булсаң, берәү дә сүзеңә игътибар кылучы булмас.

## Әдәп вә хөрмәт

Бу сыйфатлар дәхи олугка-кечегә вә барча адәмнәргә бик лязем булган сыйфатлардыр вә бала вакытыңнан ук гадәтләнә килергә тиешле сыйфатлардыр. Ягъни үзеңнән олуг кешеләргә һәрзаман кадер вә хөрмәт ит, бер олуг вә галим адәм янына барсаң, әдәп илә тор. Утыр дисә, әдәпнең шартларын ригая кылып утыр, сөйләшсәң, әдәп илә сөйләш, кулың илә, борының илә, авызың илә уйнама, кашынып-тырнанып торма, намазда торган шикелле тик тор. Колак илә вә бармагың илә ишарәт кылып сөйләмә, мондый фигыльләр олуглар каршында килешмәс. Һәр хосуста тәмам әдәп илә бул. Торышыңны-утырышыңны күргән адәмнәр «бакчы, бу бала олуглар кебек» дип мәдех вә тәхсин кылсыннар.

## *Гыйффәт вә пәрһизлек*

Бу дәхи изге холыклардан булып, һәркемгә, хосусан үсеп килә торган балаларга, бик лязем булган нәрсәдер. Ягъни кеше үзенең намусын саклап вә нәфесен тыеп, төрле-төрле вә гөнаһка төшүдән сакланмактыр, вә халык арасында рисвай була торган хәрам эшләрдән, вә явыз фигыльләрдән сакланмактыр, моны гыйффәт вә пәрһизлек диерләр. Хосусан үсеп буйга җиткәч, галим вә мулла булсаң, яки олуг бай булсаң, яки мәртәбә иясе булсаң, сиңа бу сыйфат бигрәк кирәк. Чөнки олуг вә мәртәбә иясе адәмдә гыйффәт булмаса, ягъни ул адәм үзен-үзе хәрам нәрсәләрдән вә төрле гөнаһларга төшүдән саклый белмәсә, һичбер адәм каршында аның кадере юктыр. Кечкенә башыңнан үзеңне гөнаһка төшүдән саклый кил. Нигә өйрәнсәң, аңар китәрсең. Кирәк изге, кирәк явыз холык булсын, кечкенә вакытыңнан гадәтләнә килгән булсаң, ул холык синнән картайганчы да калмас. Үзеңнең намусыңны җаның кебек сакла, үзең гөнаһ кылу түгел кешенең гөнаһка төшүенә сәбәпче булма.

## *Карендәшлек хакы*

Бу дәхи изге холыклар җөмләсеннәндер, карендәшлек вә туганлык хакын бик ригаять кылмак тиеш. Ягъни карендәшең вә туганың, яки карендәшең мәнзәлендә күрә торган адәмнәр булсын, мәхәббәт күрсәт, артларында гайбәтләренә төшмә, агай-энең илә тату бул вә башка изге мөселман карендәшләрең илә тату бул. Карендәшеңә вә якыннарыңа бер-бер төрле шатлык килсә, син дә шатлан, күңелеңдә көнчелек тотма, вә дәхи аларның башына бер-бер төрле бәла вә мәшәкать килсә, мөмкин кадәр ул бәлане вә мәшәкатьне аннан китәрергә вә ярдәм кылырга тырыш. Һичбер

карендәшең илә, башка мөселманнар илә каты-каты сөйләшмә, кычкырып сөйләшмә, йомшак кына әдәп илә сөйләш, дусларың күп булыр. Агай-эне, карендәш, олуг вә гайре мөселманнар илә өлфәт вә мәхәббәт итеп, бер-берегезгә изгелекләрегез тигәннән соң, арагызда кечкенә генә бер хәтер кала торган эшләр вакыйг булсалар, ул әүвәлге изгелекне онытырга ярамас. Бер мәртәбә изгелеге тигән адәмне һичкайчан онытма, мөмкин кадәр аның бәрабәренә изгелек кылырга тырыш. Үзеңнең балалыгыңа булышып, һичкемгә хәтер калырдай сүз әйтмә. Ике ага-эне яки ике дус арасы бозылган булса, мөмкин кадәр араларын төзәтеп килештерергә иҗтиһад кыл, бу бик гаять изге эштер.

## *Гайбәт*

Ягъни бер кешенең артында йөзенә әйтелергә ярамый торган вә үзенә хилаф төшә торган сүзне сөйләшмәк динебездә вә шәригатебездә хәрам эштер, явыз холыкларның олуграгыдыр. Җәмигъ әдъян (диннәр) каршында гайбәт хәрамдер, телеңне вә фигылеңне гайбәттән сакла. Гайбәт кылынмыш кеше хакында бу гайбәт сүз аның үзенә ишетелгәндә, ул кеше ачуланырлык вә рәнҗерлек сүз булу җәһәтеннән, яки аңа хурлык китерә торган сүз булу җәһәтеннән хәрамдыр вә дөрес түгелдер. Гәрчә үзе ишетмәсә дә, мөрәүвәт вә инсаф түгелдер, мөселманлыкка хилафтыр. Вә ул могатәб[188] адәм, ягъни ул гайбәтен сөйләнмеш адәм, моны үзе ишеткән вакытта, ихтимал, синнән интикам алмак вә ул ачуны синнән чыгармак эстәр. Телеңне вә фигылеңне гайбәттән сакламак түгел, гайбәтне күңелеңә дә китермә вә гайбәтне колагың илә һәм тыңлама да – барысы да гайбәткә язылыр.

[188] могатәб – хурланган

## *Әнаниять вә тәкәбберлек*

Ягъни мин-минлелек вә үзен югары тотмак вә башкалардан үзен артык күрмәк вә һаваланмак бик яман холыктыр вә һичбер мәзһәбтә тәкәбберлек сыйфаты мәмдух вә мәкъбүл түгелдер. Әгәрчә үзең вә мәгърифәттә, вә байлыкта, вә муллалыкта вакыйган кешедән әгъла булсаң да, тәвәзыйглыклы булмак вә үзеңне кешедән түбән тотмак ляземдер. Әгәр хасыятең булса, син кечелек кылсаң да, сине югары күтәрерләр. Күп кешеләр, үзен болай түбән тотып тәвәзыйглык иткән адәмнәр, бик олуг дәрәҗәләргә җиттеләр. Вә тәкәбберлек итеп үзен олуг тоткан кешеләр хур вә хәкыйрь булдылар. Тәкәбберлек бик яман холыктыр вә шәйтан фигыледер. Кече яшьтән үк тәвәзыйглыклы була күр. Һәркайда тәвәзыйглыклы кеше кадерле буладыр, тәкәбберләнгән вә һаваланган кешене берәү дә яратмыйдыр. Имде изге вә явыз холыкларның бәгъзеләрен сиңа бераз белдергәннән соң, мәгълүм улды ки, югарыда мәзкүр сиңа тиешсез мәсьәләне сорарга ашыкма дип әйткәнемнән морадым ошбудыр ки: динебездә вә шәригатебездә мәшруг булган вә нәмәшруг булган фигыльләрнең тәртибе вә дәрәҗәсе бардыр. Гыйбадәттә вә мөгамәләдә иң әүвәл Коръән аяте илә сабит булган фарыз эшләрне белмәк кирәк. Вә голямадан мәсьәлә сораганда да, фарыз эшләргә мөтәгалликъ[189] булган мәсьәләне сорамак кирәк. Аннан соң важиб эшләрне, аннан соң сөннәтләрне, мөстәхәбләрне[190], аннан соң мөбах[191] булган нәрсәләрне белмәк тиешле. Фарыз эшләрне белми торып мөбах эшләрдән мәсьәлә соравының ни файдасы бар! Мәслә, өстеңдә фарыз эшләр өелеп ятсын, нәфел[192] шөгыльләнүнең вәҗһе юк бер дә. Вә кәзалик

[189] мөтәгалликъ – бәйле, мөнәсәбәтле, караган
[190] мөстәхәб – яхшы күрелә торган эш
[191] мөбах – тыелмаган да, кушылмаган да эш
[192] нәфел – яхшы эшләр

гыйбадәттә вә мөгамәләдә иң әүвәл Коръән аяте илә сабит булган хәрам эшләрне белеп сакланмак кирәк, аннан соң шөбһәле нәрсәләрнең хөкемен белергә тиеш. Белмәгәнлектән, олуг хәрам булган нәрсәләрне кылып, кечкенә генә шөбһәле нәрсә хосусында мәсьәлә сорамакның ни мәгънәсе бар?!

## *Нәсихәт*

Инде әй газиз бала! Әгәр югарыда мәзкүр холыкларны укып фәһемләгән булсаң, сиңа тәкрар нәсихәт кылаем, әле син хәзердә кечкенә бала, үсәрсең, зур булырсың, фарыз вә ваҗиб эшләр өстеңә йөкләнер. Әгәр дә фасикъ булсаң, гөнаһ камытлары муеныңа киертелер. Мондый эшләрне белгәннән соң, кечкенә вакытыңнан ук изге юлга аяк бас. Имде агяһ бул: коры тел илә генә шөкер дип әйтү шөкер түгелдер. Ходай Тәгалә биргән нигъмәтнең вә һәрбер әгъзаның шөкере бардыр. Малыңнан тиешле урынга ингам-ихсан кылмак, вә садака-хәер бирмәк мал шөкередер. Гаҗизләргә ярдәм итмәк вә булышмак кул шөкередер. Дусларга зиярәт кылмак аяк шөкередер. Күз шөкере Аллаһы Тәгаләдән куркып егъламак вә Коръәнгә карап укымактыр. Коръән укыганны тыңламак колак шөкередер. Ходай Тәгаләнең дәрденә мөштак[193] булмак күңел шөкередер. Вә дәхи Коръән укымак тел шөкередер. Ходай Тәгаләгә шөкер кыл, Ходай Тәгалә үзе нигъмәтеңне арттырыр. Сүзне сөйләсәң, уйлап сөйләш, сүз авызыңнан чыккач, кире кайтарып ала алмассың. Авыздан чыккан сүз җәядән аткан ук кебектер. Вә дәхи Ходадан килгән казаны кире кайтарып җибәрә алмассың. Каза килсә, сабыр итмәк кирәк. Каза килмәс борын саклап агяһ булмак кирәк. Үткән гомерең һәм кире

[193] мөштак – омтылучы

кайтмас, аны яхшы бел, гомереңне һич файдасыз заегъ[194] уздырма. Бигрәк адәмне дүрт нәрсә картайта вә сыныклык китерәдер ки: күп дошман, күп бурыч, күп гөнаһ, күп бала-чага. Бурыч итмә, мөмкин кадәре. Тапсаң, аша, тапмасаң, ач тор. Бурычың булмасын. Рәхәт булырсың, халык арасында йөз суың китмәсен, абруйлы булырсың. Ялган сөйләшмә, кеше бер сүз әйтсә, җиңеллек кылып, тиз үк ачуланып китмә, кадереӊ булмас. Әйткән вәгъдәңә хилафлык кылма, хыянәттән ерак бул, халык сине кадер итәр. Халык арасында изге исмем булсын дисәң, һичкемгә яман вә кабахәт сүз әйтмә, азрак кына малың булса да, юмартлык кыл, юмартлыгың илә дәхи халык арасында кадереӊ артыр. Һичкемнең гаебен халык арасында йөзенә әйтмә, пәрдәсен ертма, үгет-нәсихәт кылмакчы булсаң, аулакта үгет бир. Халык арасында аның гаебен әйтеп оялтма, шулай башкалар да сине оялтмаслар. Һәркемнең гакылына күрә сүз сөйләш вә дәрәҗәсенә күрә кадер ит, берәүне дәрәҗәңнән артык кадер итсәң, үз кадереӊ җуелыр. Канәгатьсез кешене бөтен дөнья малы да туйдырмас, азга канәгать кыл, канәгать зур байлыктыр. Канәгатьсезлегеӊ сәбәпле ризыгың артмас. Көн-төн Ходай Тәгаләдән куркучы бул. Ходай Тәгалә сиңа күңелеңә килмәгән рәхмәтләрен салыр. Кече күңелле бул, үзеңнән олугларга түбәнчелек кыл, тәкәбберлек кылма. Тәкәббер кешене һичкем яратмас, байлыгың өчен тәкәбберләнмә. Байлыкка ышаныч юк, иртә килер, кич китәр. Матурлыгың өчен тәкәбберләнмә, матурлык һәм бер чәчәк кебек иртә илә ата, өйләгә кадәр җомылып корып китә. Гыйлемеӊ илә тәкәбберләнмә, синнән артык галимнәр бар... Изгеләр сохбәтеннән аерылма, үгет-нәсихәтне колагыңа алучан бул, олуг димә, кече димә, һәркемнән бер гыйбрәт ал. Гыйлем әһеленең сохбәтеннән вә галимнәрдән ерак булма, алар сиңа үзләре өйрәтмәсәләр дә,

[194] заегъ – әрәм

сөхбәтләренең әсәре сиңа тияр. Ислемай сатучы катында торасың, ул сиңа бер тамчы да бирми, бирмәсә дә, хуш исе борынга керәдер. Наданнар катында тормак, наданнар илә сөхбәт кылмак, тимерче катында тормак илә бәрабәрдер. Тимер сукканда очкыннары сиңа чәчрәп тияр, кәзалик наданның кәсафәте[195] һәм тими булмас. Галим бул, әүлия бул, суфи бул, бай бул, һөнәр иясе бул, үзеңне ким күр, изгелеге булмаган кешене үлек илә бәрабәр дип бел. Берәү синең гаебеңне аулакта үзеңә әйтсә, аңар рәхмәт әйт. Ул сиңа юл күрсәтә, караңгылыктан сине яктылыкка чыгарадыр. Изгелеккә юл күрсәткән кешене газиз тот, кеше кулындагы малга көнчелек кылма. Кешенең нәрсәсенә көнчелек кылган кешенең борынына оҗмах исе кермәс. Сиңа ни-нәрсәне Ходай Тәгалә хәрам кылды, барчасыннан ерак бул, шәригатьтә нинди килешми торган эш бар, ул эш тирәсендә әйләнмә. Ачык йөзле, татлы сүзле бул. Күп фикер, сагыш илә үзеңне бетермә. Изге гамәл кыл, ләкин гамәлеңә таянма. Гамәл кылмак синнән, кабул кылмак Аллаһы Тәгаләдән. Гамәл кыл, Ходаның үзенә тапшыр. Чытык йөзле егълак кешедән хаҗәт теләмә, фәкыйрь-фокарадан, хәерчеләрдән икмәк сатып алма, фәкыйрьлек китерер. Берәүгә ачуың килсә, ачуыңны йот, үч алам дип әйтмә. Ачуың басылмыйча бер эшкә дә керешмә. Ачу йотмак падишаһлар һөнәредер. Юкка-барга ачуланучан булма. Һич өндәмәгән, чакырмаган җиргә, зыяфәткә барма, кунак булма, бу сиңа хурлык китерер. Бер мәҗлестә синең сүзеңә колак салып тыңлаучылар булмаса, алтын кебек сүзең булса да, әйтмә. Сүзең мәкъбүл булса, әйт. Дошманнан хаҗәт теләмә, фәкыйрьдән хаҗәт теләмә, үзеңә хурлык китерерсең. Ни теләсәң, Ходайдан телә. Халык кулында һичнәрсә юктыр. Халык кулыннан сиңа файда да зарар да килмәс. Һәр ни килсә, Аллаһы Тәгалә кыладыр. Һәр эшеңне Аллаһы Тәгаләгә тапшыр: бәндәнең Ходайдан

---

[195] кәсафәт – начарлык, зарар

